# РӘСӘЙ ФЕДЕРАЦИЯСЕ

# ЭЧКЕ ЭШЛӘР ОРГАННАРЫНДА, ЯНГЫНГА КАРШЫ ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТЕНДӘ, НАРКОТИК ДАРУЛАР ҺӘМ ПСИХОТРОП МАТДӘЛӘР ӘЙЛӘНЕШЕН КОНТРОЛЬДӘ ТОТУ ОРГАННАРЫНДА, ҖИНАЯТЬ-БАШКАРМА СИСТЕМАСЫ ОЕШМАЛАРЫНДА ҺӘМ ОРГАННАРЫНДА, РӘСӘЙ ФЕДЕРАЦИЯСЕ МИЛЛИ ГВАРДИЯСЕ ГАСКӘРЛӘРЕНДӘ ХЕЗМӘТ ИТКӘН, ХӘРБИ ХЕЗМӘТ ИТКӘН ЗАТЛАРНЫ ҺӘМ АЛАРНЫҢ ГАИЛӘЛӘРЕН ПЕНСИЯ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ТУРЫНДА

## ФЕДЕРАЛЬ КАНУН

## I Бүлек. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

### Маддә 1. Әлеге Канунның гамәлдә булуы кагыла торган затлар

(03.07.2016 нән 227-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

Әлеге Канунда каралган пенсия белән тәэмин итү шартлары, нормалары һәм тәртибе

а) түбәндәге категориядәге затларга кагыла:

Рәсәй Федерациясе Кораллы Көчләрендә һәм Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлеге Берләшкән Кораллы Көчләрендә, Федераль чик буе хезмәтендә һәм Рәсәй Федерациясе чик буе хезмәте органнарында, эчке һәм тимер юл гаскәрләрендә, Рәсәй Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләрендә, хөкүмәт элемтә һәм мәгълүмат федераль органнарында, гражданнар оборонасы гаскәрләрендә, иминлек (контрразведка) хезмәтенең федераль органнарында һәм чик буе гаскәрләрендә, тышкы разведка органнарында, хәрби прокуратура органнарында, Рәсәй Федерациясе Тикшерү комитетының хәрби тикшерү органнарында, дәүләт саклыгы органнарында, Рәсәй Федерациясе кануннары нигезендә барлыкка килгән Рәсәй Федерациясенең башка хәрби оешмаларында офицерлар, прапорщиклар, мичманнар буларак хәрби хезмәт иткән затлар яки солдатлар, матрослар, сержантлар, старшиналар буларак контракт буенча хәрби хезмәт иткән затлар һәм әлеге

затларның гаиләләре (әлеге маддәнең "б" пунктында күрсәтелгән затлардан һәм аларның гаиләләреннән тыш);

(04.06.2014 нән 145-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

Хәрби Көчләрдә, Дәүләт иминлеге комитеты органнарында һәм гаскәрләрендә, эчке һәм тимер юл гаскәрләрендә, элекке ССҖБнең башка хәрби оешмаларында офицер составында булган, прапорщиклар, мичманнар буларак хәрби хезмәт иткән затлар һәм әлеге затларның гаиләләре (әлеге маддәнең "б" пунктында күрсәтелгән затлардан һәм аларның гаиләләреннән тыш);

Рәсәй Федерациясенең, элекке ССҖБнең эчке эшләр органнарында, Янгынга каршы дәүләт хезмәтендә, наркотик дарулар һәм психотроп матдәләр әйләнешен контрольда тоту органнарында, җинаять-башкарма системасының оешмаларында һәм органнарында, Рәсәй Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләрендә хезмәт иткән гади һәм җитәкче составның затлары һәм әлеге затларның гаиләләре (әлеге маддәнең "б" пунктында күрсәтелгән затлардан һәм аларның гаиләләреннән тыш);

(04.06.2014 нән 145-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

әлеге Канунның 4 маддәсендә күрсәтелгән башка дәүләтләрнең эчке эшләр органнарында, наркотик дарулар һәм психотроп матдәләр әйләнешен контрольдә тоту органнарында, җинаять-башкарма системасының оешмаларында һәм органнарында хәрби хезмәт иткән, хезмәт иткән затлар һәм әлеге затларның гаиләләре, әгәр дә Рәсәй Федерациясе яки элекке ССҖБ һәм шул дәүләтләр арасында төзелгән социаль тәэмин итү турында килешүләр тарафыннан алар яши торган дәүләт канунчылыгы нигезендә аларга пенсия белән тәэмин итү каралган булса.

б) Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлегенә кермәгән һәм ССҖБнең элекке республикалары булган илләрдә яшәүче Рәсәй Федерациясе Кораллы Көчләрендә, Федераль чик буе хезмәтендә һәм Рәсәй Федерациясенең чик буе хезмәте органнарында, эчке һәм тимер юл гаскәрләрендә, Рәсәй Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләрендә, хөкүмәт элемтә һәм мәгълүмат федераль органнарында,

гражданнар оборонасы гаскәрләрендә, иминлек (контрразведка) хезмәтенең федераль органнарында һәм чик буе гаскәрләрендә, тышкы разведка органнарында, Рәсәй Федерациясенең һәм элекке ССҖБнең башка хәрби оешмаларда, канунчылык нигезендә барлыкка килгән җинаять-башкарма системасының оешмаларында һәм органнарында, Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлеге Берләшкән Кораллы Көчләрендә офицерлар, прапорщиклар, мичманнар буларак хәрби хезмәт иткән затлар яки солдатлар, матрослар, сержантлар, старшиналар буларак контракт буенча хәрби хезмәт иткән затлар, шулак ук Рәсәй Федерациясенең, элекке ССҖБнең эчке эшләр органнарында, наркотик дарулар һәм психотроп матдәләр әйләнешен контрольда тоту органнарында, Янгынга каршы дәүләт хезмәтендә, җинаять-башкарма системасының оешмаларында һәм органнарында, Рәсәй Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләрендә хезмәт иткән гади һәм җитәкче составның затлары һәм әлеге затларның гаиләләре, әгәр дә күрсәтелгән илләрнең канунчылыгы тарафыннан аларны пенсия белән тәэмин итү эчке эшләр органнарында хезмәт иткән, хәрби хезмәт иткән затлар һәм аларның гаиләләре өчен билгеләнгән нигезләр буенча каралмаган булса.

(01.07.2017 нән 154-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

**Маддә 2. Эчке эшләр органнарында, Янгынга каршы дәүләт хезмәтендә, наркотик дарулар һәм психотроп матдәләр әйләнешен контрольда тоту органнарында, җинаять-башкарма системасының оешмаларында һәм органнарында, Рәсәй Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләрендә хезмәт иткән, хәрби хезмәт иткән затларга һәм аларның гаиләләренә "Рәсәй Федерациясендә дәүләт пенсия белән тәэмин итү турында" һәм "Иминият пенсияләре турында" Федераль кануннарында билгеләнгән нигезләрдә пенсияне билгеләү**

(21.07.1998 нән 117-ФЗ номерлы, 01.06.1999 нән 110-ФЗ номерлы 25.07.2002 нән 116-ФЗ номерлы, 30.06.2003 нән 86-ФЗ номерлы, 22.08.2004 нан 122-ФЗ номерлы (29.12.2004 нән рекдакциядә), 03.12.2007 нән 319-ФЗ номерлы, 21.07.2014

нән 216-ФЗ номерлы, 03.07.2016 нән 227-ФЗ номерлы, 01.07.2017 нән 154-ФЗ номерлы Федераль кануннар редакциясендә)

Хәрби көчләрдә һәм әлеге канунның 1 маддәсенең "а" пунктында күрсәтелгән хәрби оешмаларда хәрби хезмәткә чакыру буенча солдатлар, матрослар, сержантлар, старшиналар буларак хәрби хезмәт (элегрәк – чын сроклы хәрби хезмәт) иткән затларны һәм әлеге затларның гаиләләрен пенсия белән тәэмин итү 2001 елның 15 декабреннән 166-ФЗ номерлы "Рәсәй Федерациясендә дәүләт пенсия белән тәэмин итү турында" Федераль канун (алга таба – "Рәсәй Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында" Федераль канун) нигезендә гамәлгә ашырыла.

(01.06.1999 нән 110-ФЗ номерлы, 22.08.2004 нан 122-ФЗ номерлы ( 29.12.2004 нән рекдакциядә), 03.12.2007 нән 319-ФЗ номерлы Федераль кануннар редакциясендә)

2013 елның 28 декабреннән 400-ФЗ номерлы "Иминият пенсияләре турында" Федераль канун тарафыннан (алга таба – "Иминият пенсияләре турында" Федераль канун) һәм "Рәсәй Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты итү турында" Федераль канун тарафыннан билгеләнгән шартлар һәм нормалар буенча Рәсәй Федерациясендә яшәүче затларга һәм әлеге затларның гаиләләренә аларның теләге буенча пенсия билгеләнергә мөмкин.

(01.06.1999 нән 110-ФЗ номерлы, 22.08.2004 нан 122-ФЗ номерлы ( 29.12.2004 нән рекдакциядә), 03.12.2007 нән 319-ФЗ номерлы, 21.07.2014 нән 216-ФЗ номерлы Федераль кануннар редакциясендә)

Канунчылык тарафыннан билгеләнгән тәртиптә хәрби һәм махсус исем югалткан элекке хәрби хезмәткәрләргә һәм эчке эшләр органнарының, Янгынга каршы дәүләт хезмәтенең, наркотик дарулар һәм психотроп матдәләр әйләнешен контрольдә тоту органнарының, җинаять-башкарма системасы оешмаларының һәм органнарының, Рәсәй Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләреннең җитәкче составының затларына һәм аларның гаиләләренә "Иминият пенсияләре турында"

Федераль канун тарафыннан билгеләнгән нигезләрдә пенсияләр билгеләнә, әгәр дә алар күрсәтелгән канун нигезендә пенсия белән тәэмин итү хокукына ия булсалар.

(21.07.1998 нән 117-ФЗ номерлы, 01.06.1999 нән 110-ФЗ номерлы 25.07.2002 нән 116-ФЗ номерлы, 30.06.2003 нән 86-ФЗ номерлы, 22.08.2004 нан 122-ФЗ номерлы (29.12.2004 нән рекдакциядә), 03.12.2007 нән 319-ФЗ номерлы, 21.07.2014 нән 216-ФЗ номерлы, 03.07.2016 нән 227-ФЗ номерлы, 01.07.2017 нән 154-ФЗ номерлы Федераль кануннар редакциясендә)

**Маддә 3. Офицерлар буларак яки контракт буенча хәрби хезмәт иткән һәм аларның гаиләләренә тиңләштерелгән затлар**

(03.12.2007 нән 319-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

Бөек Ватан сугышы чорында совет партизан отрядларында һәм берләшмәләрендә офицерлар башкарган вазифаларга туры килгән команда вазифаларын үтәгән затларга һәм аларның гаиләләренә әлеге канунда офицерлар буларак хәрби хезмәт иткән затлар һәм аларның гаиләләре өчен каралган нигезләрдә пенсия билгеләнә. Шундый ук нигезләрдә Бөек Ватан сугышы чорында хәрби частьләрдә, штабларда һәм гамәлдәге армия оешмаларында офицерлар башкарган вазифаларга туры килгән вазифаларны үтәгән сроклы хезмәтнең элекке хәрби хезмәткәрләренә һәм аларның гаиләләренә пенсияләр билгеләнә.

(28.11.1995 нән 186-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

Сроктан тыш хәрби хезмәттә булган затларга (сроктан тыш хәрби хезмәтнең элекке хәрби хезмәткәрләренә), солдатлар, матрослар, сержантлар һәм старшиналар вазифаларында ирекле рәвештә хәрби хезмәт иткән хатын-кызларга һәм аларның гаиләләренә пенсияләр әлеге канунда контракт буенча солдатлар, матрослар, сержантлар, старшиналар буларак хәрби хезмәт иткән затлар һәм аларның гаиләләре өчен каралган нигезләрдә билгеләнә.

(02.02.2006 нән 20-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

**Маддә 4. Башка дәүләтләрнең эчке эшләр органнарында, наркотик дарулар һәм психотроп матдәләр әйләнешен контрольдә тоту органнарында, җинаять-башкарма системасы оешмаларында һәм органнарында хәрби хезмәт иткән, хезмәт иткән затларны һәм аларның гаиләләрен пенсия белән тәэмин итү**

(21.07.1998 нән 117-ФЗ номерлы, 30.06.2003 нән 86-ФЗ номерлы Федераль кануннар редакциясендә)

Рәсәй Федерациясендә яшәүче офицерлар, прапорщиклар, мичманнар, сроктан тыш хезмәтнең хәрби хезмәткәрләре буларак хәрби хезмәт иткән затларны, яки кораллы көчләрдә (армияләрдә, гаскәрләрдә), иминилек органнарында һәм канунчылык нигезендә барлыкка килгән башка хәрби оешмаларында солдатлар, матрослар, сержантлар һәм старшиналар буларак контракт буенча хәрби хезмәт иткән затларны, яисә Рәсәй Федерациясе яки элекке ССҖБ белән социаль тәэмин итү турында килешүләр төзегән Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлегенә кермәгән һәм Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлегенә кергән башка дәүләтләрнең эчке эшләр органнарында, наркотик дарулар һәм психотроп матдәләр әйләнешен контрольдә тоту органнарында, җинаять-башкарма системасы оешмаларында хезмәт иткән затларны һәм аларның гаиләләрен пенсия белән тәэмин итү шул килешүләр тарафыннан каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

(21.07.1998 нән 117-ФЗ номерлы, 30.06.2003 нән 86-ФЗ номерлы Федераль кануннар редакциясендә)

**Маддә 5. Пенсия төрләре**

Әлеге канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән затлар киләсе пенсиягә хокуклы:

а) әлеге канунда каралган хәрби хезмәттә, һәм (яки) эчке эшләр органнарында, һәм (яки) Рәсәй Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләрендә, Янгынга каршы дәүләт хезмәтендә, һәм (яки) наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр әйләнешен контрольдә тоту органнарында һәм (яки) җинаять-башкарма системасы

оешмаларында һәм органнарында хезмәт иткәндә тиешле елларны эшләгән өчен пенсиягә хокуклы;

(21.07.1998 нән 117-ФЗ номерлы, 25.07.2002 нән 116-ФЗ номерлы, 30.06.2003 нән 86-ФЗ номерлы, 01.07.2017 нән 154-ФЗ номерлы Федераль кануннар редакциясендә)

б) инвалидлык буенча пенсиягә хокуклы, әгәр дә алар әлеге канунда каралган шартларда инвалид булсалар.

Әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән затлар үлсә яки һәлак булса, аларның гаиләләре әлеге Канунда каралган шартлар буенча туендыручысын югалту очрагы буенча пенсиягә хокук ала.

Әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән затлар арасыннан үлгән пенсионерларның гаиләләре туендыручысын югалту очрагы буенча пенсиягә хәрби хезмәт үтү чорында үлгән затларның гаиләләре белән бергә гомуми нигезләрдә хокуклы.

**Маддә 6. Пенсия белән тәэмин итүгә хокукны гамәлгә ашыру**

Әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән пенсия белән тәэмин итү хокукына ия булган затларга пенсияләр алар хезмәтеннән азат ителгәннән соң билгеләнә һәм түләнә. Бу затларга инвалидлык буенча пенсияләр һәм туендыручысын югалту очрагы буенча аларның гаиләләренә пенсияләр хезмәт итүнең дәвамлылыгына карамастан билгеләнә.

Әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән затлар арасыннан пенсионерларга аларның Янгынга каршы дәүләт хезмәтенә яки җинаять-башкарма системасы органнарына һәм оешмаларына (шул исәптән теләсә кайсы башка дәүләтләрдә), Рәсәй Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләренә хәрби хезмәткә кергәндә яки хезмәткә кергәндә билгеләнгән пенсияләрне түләү хезмәт чорына туктатыла.

(икенче өлеш 28.11.1995 нән 186-ФЗ Федераль канун тарафыннан кертелгән, 21.07.1998 нән 117-ФЗ номерлы, 25.07.2002 нән 116-ФЗ номерлы, 30.06.2003 нән 86-

ФЗ номерлы, 03.07.2016 нән 227-ФЗ номерлы, 03.07.2016 нән 305-ФЗ номерлы, 01.07.2017 нән 154-ФЗ номерлы Федераль кануннар редакциясендә)

**Маддә 7. Пенсияне сайлау хокукы**

(28.11.1995 нән 186-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

Бер үк вакытта Рәсәй Федерациясе канунчылыгы нигезендә төрле пенсияләргә хокуклы булган әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән затларга һәм аларның гаиләләренә аларны сайлавы буенча бер пенсия билгеләнә (әлеге маддәдә һәм "Рәсәй Федерациясендә дәүләт пенсия белән тәэмин итү турында" Федераль канунда каралган очраклардан тыш).

(беренче өлеш 21.06.2010 нән 122-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

Әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән затларның өйләнмәгән яки кияүгә чыкмаган әлеге Канунның 21 маддәсенең "а" пунктында санап кителгән сәбәпләр аркасында һәлак булган ирләре яки хатыннары (күрсәтелгән затларның үлеме аларның хокукка каршы гамәлләре нәтиҗәсендә килеп чыкан очраклардан тыш) бер үк вакытта ике пенсия алырга хокуклы. Аларга әлеге Канунның 30 маддәсендә каралган туендыручысын югалту очрагы буенча пенсия һәм Рәсәй Федерациясе канунчылыгы нигезендә билгеләнгән башка пенсия билгеләнергә мөмкин (туендыручысын югалту очрагы буенча пенсиядән яки туендыручысын югалту очрагы буенча социаль пенсиядән тыш).

(21.12.2006 нән 239-ФЗ номерлы, 03.12.2007 нән 319-ФЗ номерлы, 08.05.2008 нан 64-ФЗ номерлы, 21.06.2010 нән 122-ФЗ номерлы Федераль кануннар редакциясендә)

Әлеге Канунның 21 маддәсенең "а" пунктында санап үтелгән сәбәпләр аркасында үлгән (һәлак булган) әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән затларның ата-аналары бер үк вакытта ике пенсия алырга хокуклы. Аларга әлеге Канунның 30 маддәсендә каралган туендыручысын югалту очрагы буенча пенсия һәм Рәсәй Федерациясе канунчылыгы нигезендә билгеләнгән башка пенсия

билгеләнергә мөмкин (туендыручысын югалту очрагы буенча пенсиядән яки туендыручысын югалту очрагы буенча социаль пенсиядән тыш).

(Өченче өлеш 01.06.1999 нән N 110-ФЗ номерлы Федераль канун тарафыннан кертелгән; в ред. 22.08.2004 нан 122-ФЗ номерлы, 03.12.2007 нән 319-ФЗ номерлы, 21.06.2010 нән 122-ФЗ номерлы Федераль кануннар редакциясендә)

Әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән затлар картлык буенча иминият пенсиясен билгеләү өчен шартлар булган очракта, әлеге Канунда каралган тиешле еллар эшләгән өчен пенсиясен яки инвалидлык буенча пенсиясен һәм "Иминият пенсияләре турында" Федераль канун нигезендә билгеләнә торган картлык буенча иминият пенсиясен (картлык буенча иминият пенсиясенә беркетелгән түләүдән тыш) бер үк вакытта алу хокукына ия.

(21.07.2014 нән 216-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

Әлеге Канунның 21 маддәсенең икенче һәм өченче өлешләрендә күрсәтелгән әлеге Канунның 21 маддәсенең "а" пунктында санап үтелгән сәбәпләр аркасында әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән затлар арасыннан ике һәм аннан күбрәк туендыручысын (ирен (хатынын) һәм (яисә) балаларын) югалткан затларга (күрсәтелгән затларның үлеме аларның хокукка каршы гамәлләре нәтиҗәсендә килеп чыккан очраклардан тыш) әлеге Канунның 30 маддәсендә каралган туендыручысын югалту очрагы буенча пенсия аларның сайлау буенча күрсәтелгән туендыручыларның берсенең үлеме (һәлак булуы) сәбәпле билгеләнә.

(01.05.2017 нан 95-ФЗ номерлы Федераль канун тарафыннан кертелгән)

**Маддә 8. Радиация йогынтысына дучар ителгән эчке эшләр органнарында, Янгынга каршы дәүләт хезмәтендә, наркотик дарулар һәм психотроп матдәләр әйләнешен контрольда тоту органнарында, җинаять-башкарма системасының оешмаларында һәм органнарында, Рәсәй Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләрендә хезмәт иткән, хәрби хезмәт иткән затларны һәм аларның гаиләләрен пенсия белән тәэмин итү**

(21.07.1998 нән 117-ФЗ номерлы, 25.07.2002 нән 116-ФЗ номерлы, 30.06.2003 нән 86-ФЗ номерлы, 03.07.2016 нән 227-ФЗ номерлы, 01.07.2017 нән 154-ФЗ номерлы Федераль кануннар редакциясендә)

Әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән атом-төш коралларның шартлаулары һәм сынаулары вакытында яки гражданнар һәм хәрби билгеләнештәге объектларда һәлакәтләр нәтиҗәсендә, шулай ук әлеге һәлакәтләрнең нәтиҗәләрен бетергәндә радиация йогынтысына дучар ителгән затларга һәм аларның гаиләләренә пенсия билгеләүнең өстәмә ташламалы шартлары бирелә, радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарны социаль яклау турында Рәсәй Федерациясенең канунчылыгы нигезендә пенсияләргә, пособиеләргә һәм компенсацияләргә өстәмәләр түләнә.

**Маддә 9. Пособиены түләү**

Әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән хезмәттән азат ителгән затларга, әлеге затлар арасыннан булган инвалидлар булучы пенсионерларга һәм үлгән пенсионерларның гаилә әгъзаларына Рәсәй Федерациясенең канунчылыгы һәм Рәсәй Федерациясе Хөкүмәтенең норматив актлары тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә һәм күләмнәрдә пособиеләр түләнә.

(28.11.1995 нән 186-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

**Маддә 10. Пенсияне түләү өчен акча**

(28.11.1995 нән 186-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

Әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән затларга һәм аларның гаиләләренә пенсияне түләү федераль бюджет акчалары исәбеннән тәэмин ителә. Шул ук вакытта пенсияне түләү чыгымнарын финанслау үзәкләштерелгән тәртиптә башкарыла.

"Иминият пенсияләре турында" Федераль канун һәм "Рәсәй Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты итү турында" Федераль канун нигезендә каралган пенсияне түләү хәрби хезмәткәрләргә, пенсия белән тәэмин итү буенча хәрби

хезмәткәрләгә тиңләштерелгән затларга һәм аларның гаиләләренә күрсәтелгән федераль кануннар нигезендә гамәлгә ашырыла.

(03.12.2007 нән 319-ФЗ номерлы, 21.07.2014 нән 216-ФЗ номерлы Федераль кануннар редакциясендә)

**Маддә 11. Пенсия белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органнары һәм федераль дәүләт органнары**

(28.11.1995 нән 186-ФЗ номерлы, 21.07.2014 нән 154-ФЗ номерлы Федераль кануннар редакциясендә)

Әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән затларны һәм аларның гаиләләрен әлеге затларның соңгы хезмәт итү урынына карап пенсия белән тәэмин итү киләсе органнар тарафыннан гамәлгә ашырыла:

а) Рәсәй Федерациясе Оборона министрлыгы тарафыннан – Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлеге Кораллы Көчләреннән, Рәсәй Федерациясе Кораллы Көчләреннән, тимер юл гаскәрләреннән, Рәсәй Федерациясе канунчылыгы нигезендә барлыкка килгән башка хәрби оешмалардан (әлеге маддәнең "б" һәм "в" пунктларда санап үтелгән оешмалардан тыш) азат ителгән хәрби хезмәтләргә, әлеге канунның 3 маддәсенең беренче өлешендә күрсәтелгән затларга һәм аларның гаиләләренә карата;

б) Рәсәй Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы тарафыннан – эчке гаскәрләрдән, Рәсәй Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләреннән һәм хәрбиләштерелгән янгын сакчылыгыннан азат ителгән хәрби хезмәткәрләргә, Рәсәй Федерациясе эчке эшләр органнарыннан, Гражданнарны саклау эшләре, гаддәттән тыш хәлләр, табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү буенча Рәсәй Федерациясе министрлыгының Янгынга каршы дәүләт хезмәтеннән, салымнар полициясенең федераль органнарыннан, наркотик дарулар һәм психотроп матдәләр әйләнешен контрольдә тоту органнарыннан, Рәсәй Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләреннән азат ителгән гади һәм җитәкче составыннан хезмәткәрләргә һәм аларның гаиләләренә карата;

(03.07.2016 нән 227-ФЗ номерлы, 03.07.2016 нән 305-ФЗ номерлы, 01.07.2017 нән 154-ФЗ номерлы Федераль кануннар редакциясендә)

в) Рәсәй Федерациясенең Федераль иминлек хезмәте тарафыннан – иминлек (контрразведка) федераль хезмәтенең органнарыннан һәм чик буе гаскәрләреннән, тышкы разведка органнарыннан, дәүләт саклыгы органнарыннан, Федераль чик буе хезмәтеннән һәм Рәсәй Федерациясе чик буе хезмәте органнарыннан, хөкүмәт элемтә һәм мәгълүмат федераль органнарыннан, махсус элемтә һәм мәгълүмат федераль органыннан, Рәсәй Федерациясе Саклау хезмәтенең баш идарәсеннән, Рәсәй Федерациясе Президентының иминлек хезмәтеннән һәм Рәсәй Федерациясе Президенты каршындагы махсус объектлар хезмәтеннән азат ителгән хәрби хезмәткәрләргә һәм аларның гаиләләренә карата;

(28.11.1995 нән 186-ФЗ номерлы, 30.06.2003 нән 86-ФЗ номерлы, 04.11.2014 нән 342-ФЗ номерлы Федераль кануннар редакциясендә)

г) Җәзаларны үтәтү федераль хезмәте тарафыннан – җинаять-башкарма системасының оешмаларыннан һәм органнарыннан азат ителгән хезмәткәрләргә һәм аларның гаилә әгъзаларына карата;

("г" пп. 21.07.1998 нән 117-ФЗ номерлы Федераль канун тарафыннан кертелгән; 30.06.2003 нән 86-ФЗ номерлы, 29.06.2004 нән 58-ФЗ номерлы федераль кануннар редакциясендә)

д) үз көчен югалткан - 03.07.2016 нән 305-ФЗ номерлы Федераль канун);

е) Рәсәй Федерациясе Генераль прокуратурасы тарафыннан – 2017 елның 1 гыйнварыннан соң хәрби прокуратура органнарыннан хәрби хезмәттән азат ителгән затларга һәм аларның гаилә әгъзаларына карата;

("е" п. 01.07.2017 нән 154-ФЗ номерлы Федераль канун тарафыннан кертелгән)

ж) Рәсәй Федерациясе Тикшерү комитеты тарафыннан – 2017 елның 1 гыйнварыннан соң Рәсәй Федерациясе Тикшерү комитетының хәрби тикшерү

органнарыннан хәрби хезмәттән азат ителгән затларга һәм аларның гаилә әгъзаларына карата.

("ж" п. 01.07.2017 нән 154-ФЗ номерлы Федераль канун тарафыннан кертелгән)

Әлеге Канунның 1 маддәсенең "б" пунктында һәм "а" пунктының өченче һәм бишенче абзацларында күрсәтелгән элекке ССҖБнең, башка дәүләтләрнең эчке эшләр органнарының, наркотик дарулар һәм психотроп матдәләр әйләнешен контрольдә тоту органнарының, җинаять-башкарма системасының органнарының һәм оешмаларының гади һәм җитәкче составыннан затларны, хезмәтеннән азат ителгән хәрби хезмәткәрләрнең тиешле категорияләрен һәм аларның гаиләләрен пенсия белән тәэмин итү әлеге маддәда каралган идарә тарамагына караган мөнәсәбәттә булу нигезендә гамәлгә ашырыла.

(21.07.1998 нән 117-ФЗ номерлы, 30.06.2003 нән 86-ФЗ номерлы Федераль кануннар редакциясендә)

**Маддә 12. Өстәмә социаль гарантияләр**

(22.08.2004 нән 122-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

Рәсәй Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары үз вәкаләтләре чикләрендә үз бюджетлары акчалары хисабына Рәсәй Федерациясе территориясендә яшәүче әлеге Канунның 1 маддәсенең "а" пунктында күрсәтелгән затлар арасыннан булган пенсионерларга һәм аларның гаилә әгъзаларына өстәмә социаль гарантияләр билгели ала.

(03.12.2007 нән 319-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

## Бүлек II. ТИЕШЛЕ ЕЛЛАР ЭШЛӘГӘН ӨЧЕН ПЕНСИЯ

**Маддә 13. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә хокукны билгели торган шартлар**

Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия алу хокукына киләселәр ия:

а) әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән эштән азат ителгән көнгә эчке эшләр органнарында хәрби хезмәттә һәм (яки) хезмәттә, һәм (яки) Янгынга каршы дәүләт хезмәтендә хезмәттә, һәм (яки) җинаять-башкарма системасы оешмаларында һәм органнарында хезмәттә, наркотик дарулар һәм психотроп матдәләр әйләнешен контрольдә тоту органнарында хезмәттә, һәм (яки) Рәсәй Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләрендә хезмәттә 20 ел һәм аннан да күбрәк тиешле еллар эшләгән затлар;

(21.07.1998 нән 117-ФЗ номерлы, 25.07.2002 нән 116-ФЗ номерлы, 30.06.2003 нән 86-ФЗ номерлы, 03.07.2016 нән 227-ФЗ номерлы, 01.07.2017 нән 154-ФЗ номерлы Федераль кануннар редакциясендә)

б) әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән сәламәтлек хәле яки организацион-штат чаралары сәбәпле хезмәттә иң чик яшькә җиткәнче эштән азат ителгән һәм эштән азат итү көненә 45 яшькә җиткән, 25 календарь ел һәм аннан күбрәк хезмәт стажы булган затлар, шуларның 12 ел һәм алты айдан да ким түгел срогын эчке эшләр органнарында хәрби хезмәт һәм (яки) хезмәт итү, һәм (яки) Янгынга каршы дәүләт хезмәтендә хезмәт итү, һәм (яки) наркотик дарулар һәм психотроп матдәләр әйләнешен контрольдә тоту органнарында хезмәт итү, һәм (яки) җинаять-башкарма системасы оешмаларында һәм органнарында хезмәт итү, һәм (яки) Рәсәй Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләрендә хезмәт итү тәшкил итсә.

(28.11.1995 нән 186-ФЗ номерлы, 21.07.1998 нән 86-ФЗ номерлы, 25.07.2002 нән 116-ФЗ номерлы, 30.06.2003 нән 86-ФЗ номерлы, 03.07.2016 нән 227-ФЗ номерлы, 01.07.2017 нән 154-ФЗ номерлы Федераль кануннар редакциясендә)

Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә хокукны билгеләгәндә әлеге маддәнең беренче өлешенең "б" пункты нигезендә гомуми хезмәт стажына киләселәр кертелә:

а) "Рәсәй Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында" Федераль канун үз көченә кергән көнгә кадәр дәүләт пенсияләрен билгеләү һәм яңадан исәпләү өчен билгеләнгән тәртиптә исәпләнгән һәм расланган хезмәт стажы;

б) "Иминият пенсияләре турында" Федераль канун үз көченә кергән көнгә кадәр "Рәсәй Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында" Федераль канунда каралган хезмәт пенсияләрен билгеләү һәм яңадан исәпләү өчен билгеләнгән тәртиптә исәпләнгән һәм расланган иминият стажы;

(21.07.2014 нән 216-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

в) "Иминият пенсияләре турында" Федераль канун нигезендә иминият пенсияләрен билгеләү һәм яңадан исәпләү өчен билгеләнгән тәртиптә билгеләнгән һәм расланган иминият стажы.

("в" п. 21.07.2014 нән 216-ФЗ Федераль канун тарафыннан кертелгән)

(икенче өлеш 03.12.2007 нән 319-ФЗ номерлы Федераль канун тарафыннан кертелгән)

**Маддә 14. Пенсия күләме**

Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

а) әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән тиешле 20 ел һәм аннан да күбрәк эшләгән затларга: тиешле 20 ел эшләгән өчен – әлеге Канунның 43 маддәсендә каралган акчалата тәэмин итүнең тиешле суммаларның 50 проценты; 20 елдан артык эшләгән очракта һәр киләсе ел өчен – акчалата тәэмин итүнең күрсәтелгән суммаларның 3 проценты, әмма бу суммаларның проценты 85 проценттан артмаска тиеш;

б) әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән 25 календарь ел һәм аннан да күбрәк гомуми хезмәт стажы булган затларга, аларның 12 ел һәм алты ай да ким булмаган срогын эчке эшләр органнарында хәрби хезмәт һәм (яки) хезмәт итү, һәм (яки) Янгынга каршы дәүләт хезмәтендә хезмәт итү, һәм (яки) наркотик дарулар һәм психотроп матдәләр әйләнешен контрольдә тоту органнарында хезмәт итү, һәм (яки) җинаять-башкарма системасы оешмаларында һәм органнарында хезмәт итү, һәм (яки) Рәсәй Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләрендә хезмәт итү тәшкил итсә: 25 ел гомуми хезмәт стажы өчен – әлеге Канунның 43 маддәсендә каралган акчалата

тəэмин итүнең 50 проценты; 25 елдан артык стажның һəр елы өчен – акчалата тəэмин итүнең күрсəтелгəн суммаларының 1 проценты.

(21.07.1998 нəн 117-ФЗ номерлы, 25.07.2002 нəн 116-ФЗ номерлы, 30.06.2003 нəн 86-ФЗ номерлы, 03.07.2016 нəн 227-ФЗ номерлы, 01.07.2017 нəн 154-ФЗ номерлы Федераль кануннар редакциясендə)

Əлеге маддəдə күрсəтелгəн пенсия алган затлар эчке эшлəр органнарына, яки Янгынга каршы дəүлəт хезмəтенə, яки җинаять-башкарма системасы оешмаларына һəм органнарына, яки Рəсəй Федерациясе милли гвардиясе гаскəрлəренə хəрби хезмəткə яки хезмəткə кабат билгелəнсə, алга таба эштəн азат ителгəндə аларга пенсия түлəү соңгы эштəн азат ителгəн көнгə гомуми хезмəт стажыннан һəм тиешле еллар эшлəгəннəн чыгып яңартыла.

(21.07.1998 нəн 117-ФЗ номерлы, 25.07.2002 нəн 116-ФЗ номерлы, 30.06.2003 нəн 86-ФЗ номерлы, 03.12.2007 нəн 319-ФЗ номерлы, 03.07.2016 нəн 227-ФЗ номерлы, 01.07.2017 нəн 154-ФЗ номерлы Федераль кануннар редакциясендə)

**Маддə 15. Тиешле еллар эшлəгəн өчен пенсиянең минималь күлəме**

(03.12.2007 нəн 319-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендə)

Əлеге Канун нигезендə билгелəнгəн тиешле еллар эшлəгəн өчен пенсия əлеге канунның 46 маддəсенең беренче өлешендə күрсəтелгəн пенсиянең исəплəү күлəменең 100 процентыннан кимрəк була алмый.

**Маддə 16. Инвалидларга тиешле еллар эшлəгəн өчен пенсия күлəмен арттыру**

(03.12.2007 нəн 319-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендə)

Əлеге Канунның 1 маддəсендə күрсəтелгəн затларга билгелəнə торган тиешле елларны эшлəгəн өчен пенсиялəр килəсе затларга арта:

а) Хəрби яралану аркасында инвалид булган затларга:

I төркем инвалидларга – әлеге канунның 46 маддәсенең беренче өлешендә күрсәтелгән пенсиянең исәпләү күләменең 300 процентына арта;

II төркем инвалидларга – әлеге канунның 46 маддәсенең беренче өлешендә күрсәтелгән пенсиянең исәпләү күләменең 250 процентына арта;

III төркем инвалидларга – әлеге канунның 46 маддәсенең беренче өлешендә күрсәтелгән пенсиянең исәпләү күләменең 175 процентына арта;

б) Гомуми авыру, хезмәт имгәнүе һәм башка сәбәпләр аркасында инвалид булган (инвалидлыклары канунга каршы гамәлләре аркасында килеп чыккан затлардан тыш) һәм 1995 елның 12 гыйнварыннан 5-ФЗ номерлы "Ветераннар турында" Федераль канунның (алга таба – "Ветераннар турында" Федераль канун) 2 маддәсенең 1 пунктының "и" пунктасчасында һәм "а" - "ж" пунктачаларында күрсәтелгән затлар исәбеннән Бөек Ватан сугышы катнашучылары булган затларга:

I төркем инвалидларына – әлеге канунның 46 маддәсенең беренче өлешендә күрсәтелгән пенсиянең исәпләү күләменең 250 процентына арта;

II төркем инвалидларына – әлеге канунның 46 маддәсенең беренче өлешендә күрсәтелгән пенсиянең исәпләү күләменең 200 процентына арта;

III төркем инвалидларына – әлеге канунның 46 маддәсенең беренче өлешендә күрсәтелгән пенсиянең исәпләү күләменең 150 процентына арта;

в) гомуми авыру, хезмәт имгәнүе һәм башка сәбәпләр аркасында инвалид булган (инвалидлыклары канунга каршы гамәлләре аркасында килеп чыккан затлардан тыш) "Блокадалы Ленинградта яшәүче" билгесе белән бүләкләнгән затларга:

I төркем инвалидларына – әлеге канунның 46 маддәсенең беренче өлешендә күрсәтелгән пенсиянең исәпләү күләменең 200 процентка арта;

II төркем инвалидларына – әлеге канунның 46 маддәсенең беренче өлешендә күрсәтелгән пенсиянең исәпләү күләменең 150 процентына арта;

III төркем инвалидларына – әлеге канунның 46 маддәсенең беренче өлешендә күрсәтелгән пенсиянең исәпләү күләменең 100 процентына арта.

("в" п. 13.02.2008 нән 3-ФЗ номерлы Федераль канун тарафыннан кертелгән)

**Маддә 17. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә өстәмә түләүләр**

(03.12.2007 нән 319-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

Әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән затларга билгеләнә торган тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә (шул исәптән минималь күләмдә исәпләнгән пенсиягә) түбәндәге өстәмә түләүләр исәпләнә:

а) I төркем инвалид булган яки 80 яшькә җиткән пенсионерларга – аларны карау өчен әлеге канунның 46 маддәсенең беренче өлешендә күрсәтелгән пенсиянең исәпләү күләменең 100 процентына күләмендә;

(24.07.2009 нән 213-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

б) асрауларында әлеге Канунның 29 маддәсенең өченче өлешенең "а", "б" һәм "г" пунктларында һәм 31, 33 һәм 34 маддәләрендә күрсәтелгән гаиләнең эшкә яраксыз әгъзалары торган эшләми торган пенсионерларга:

мондый бер гаилә әгъзасы булса – әлеге канунның 46 маддәсенең беренче өлешендә күрсәтелгән пенсиянең исәпләү күләменең 32 проценты күләмендә;

мондый ике гаилә әгъзасы булса – әлеге канунның 46 маддәсенең беренче өлешендә күрсәтелгән пенсиянең исәпләү күләменең 64 проценты күләмендә;

мондый өч һәм аннан да күбрәк гаилә әгъзасы булса – әлеге канунның 46 маддәсенең беренче өлешендә күрсәтелгән пенсиянең исәпләү күләменең 100 проценты күләмендә;

Күрсәтелгән өстәмә түләү иминият яки социаль пенсия алмаган гаилә әгъзаларына гына исәпләнә;

(21.07.2014 нән 216-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

в) Инвалидлар булмаган 1995 елның 12 гыйнварыннан 5-ФЗ номерлы "Ветераннар турында" Федераль канунның 2 маддәсенең 1 пунктының "и" пунктасчасында һәм "а" - "ж" пунктачаларында күрсәтелгән затлар исәбеннән Бөек Ватан сугышы катнашучылары булган пенсинерларга – әлеге канунның 46 маддәсенең беренче өлешендә күрсәтелгән пенсиянең исәпләү күләменең 32 проценты күләмендә, аларның саныннан булган 80 яшькә җиткән затларга – пенсиянең исәпләү күләменең 64 проценты күләмендә.

Әлеге маддәнең беренче өлешенең "в" пунктында каралган өстәмә түләү әлеге Канунның 16 маддәсендә каралган арттыру белән исәпләнгән пенсиягә исәпләнми.

**Маддә 18. Пенсияне билгеләү өчен тиешле еллар эшләгәнне исәпләү**

Әлеге Канунның 13 маддәсенең "а" пункты нигезендә пенсияне билгеләү өчен тиешле еллар эшләгәнгә түбәндәгеләр керә: хәрби хезмәт; эчке эшләр органнарында, Янгынга каршы дәүләт хезмәтендә, наркотик дарулар һәм психотроп матдәләр әйләнешен контрольдә тоту органнарында хезмәт итү гади һәм җитәкче состав вазифаларында хезмәт итү; җинаять-башкарма системасы оешмаларында һәм органнарында хезмәт итү; Рәсәй Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләрендә хезмәт итү; совет партизан отрядларында һәм берләшмәләрендә хезмәт итү; дәүләт хакимияте һәм идарә органнарында, гражданлык министрлыкларында, ведомстволарда һәм оешмаларда хәрби хезмәттә калып яки Рәсәй Федерациясенең Эчке эшләр министрлыгы кадрларында, наркотик дарулар һәм психотроп матдәләр әйләнешен контрольдә тоту органнарында, җинаять-башкарма системасы оешмаларында һәм органнарында калып эшләү вакыты; Рәсәй Федерациясенең Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Янгынга каршы дәүләт хезмәте системасында (Эчке эшләр министрлыгының янгын сүндерү хезмәтендә, Эчке эшләр министрлыгының янгынга каршы һәм авария-коткару хезмәтләрендә, Рәсәй Федерациясенең Эчке эшләр министрлыгының Янгынга каршы дәүләт хезмәтендә) аларның гади һәм җитәкче составының затлары һәм Янгынга каршы дәүләт хезмәте хезмәткәрләре тарафыннан башкаручы вазифаларына билгеләүгә кадәр эш вакыты;

әсирлектә булу вакыты, әгәр әсирлеккә китү ирекле булмаса һәм хәрби хезмәткәр Ватанга каршы җинаять кылмаса; җинаять җаваплылыгына нигезсез җәлеп ителгән яисә нигезсез репрессияләнгән һәм соңыннан реабилитацияләнгән гади һәм җитәкче составынан булган затларның, хәрби хезмәткәрләрнең җәзаларын алу һәм төрмәдә булу вакыты. Эчке эшләр органнарыннан, Янгынга каршы дәүләт хезмәтеннән, наркотик дарулар һәм психотроп матдәләр әйләнешен контрольдә тоту органнарыннан, Рәсәй Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләреннән хезмәттән азат ителгән офицерларына һәм җитәкче составында булган затларга пенсияне билгеләү өчен тиешле еллар эшләгәнгә аларның хезмәткә билгеләгәнче (әмма биш елдан артык түгел) уку вакыты да саналырга мөмкин, бер ел уку алты ай хезмәт өчен исәпләнә.

(03.07.2016 нән 227-ФЗ номерлы, 01.07.2017 нән 154-ФЗ номерлы Федераль кануннар редакциясендә)

Аерым шартларда хезмәт итү вакыты әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән затларга пенсияне билгеләү өчен тиешле еллар эшләгәнгә льготалы исәпләүдә алынырга тиеш.

Әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән затларга пенсияне билгеләү өчен тиешле еллар эшләгәнне исәпләү тәртибе Рәсәй Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

(28.11.1995 нән 186-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

## Бүлек III. ИНВАЛИДЛЫК БУЕНЧА ПЕНСИЯ

### Маддә 19. Инвалидлык буенча пенсиягә хокукны билгели торган шартлар

Әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән инвалид булып калган затлар инвалидлык буенча пенсиягә хокуклы, әгәр инвалидлыклары хезмәт үткән чорда яисә хезмәттән азат ителгәннән соң өч айдан да соңга калмыйча барлыкка килсә,

яисә инвалидлык шул вакыттан соңрак барлыкка килсә дә әмма хезмәт үткән чорда алынган яралану, контузия, гарипләнү яки авыру нәтиҗәсендә барлыкка килсә.

**Маддә 20. Инвалидлыкны билгеләү**

(03.12.2007 нән 319-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

Инвалидлык төркеме һәм сәбәпләре, инвалидлыкның барлыкка килү вакыты һәм инвалидлык вакыты медицина-социаль экспертиза федераль оешмалары тарафыннан билгеләнә.

(24.07.2009 нән 213-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

**Маддә 21. Инвалидлар категориясе**

(28.11.1995 нән 186-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

Әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән затлар арасыннан инвалидлар инвалидлык сәбәпләренә чыгып түбәндәге категориягә бүленә:

а) хәрби яралану аркасында инвалидлар – Ватанны саклаганда барлыкка килгән, шул исәптән фронтта булу, сугыш хәрәкәтләре барган дәүләтләрдә хезмәт итү яки алар тарафыннан хәрби хезмәтнең башка бурычларын (хезмәт вазифаларын) үтәү сәбәпле алынган яралану, контузия, имгәнү яки авырулар нәтиҗәсендә инвалид булган затлар. Хәрби яралану аркасында инвалидларга шулай ук токтында яки гамәлдәге армиядә тәрбияләнүчеләр һәм юнглар буларак булган вакытта барлыкка килгән яралану, контузия, имгәнү яки авырулар нәтиҗәсендә инвалид булган элекке хәрби хезмәткәрләр керә (әлеге Канунның 18 маддәсенең беренче өлешендә каралган шартларны үтәгәндә);

б) хәрби хезмәт (хезмәт) вакытында барлыкка килгән авыру аркасында инвалидлар – хәрби хезмәт бурычларын (хезмәт бурычларын) үтәүгә бәйле булмаган бәхетсезлек очрагыннан соң имгәнү нәтиҗәсендә инвалид булган затлар яисә хәрби хезмәт бурычларын (хезмәт бурычларын) үтәүгә бәйле булмаган авырулар аркасында инвалид булган затлар. Хәрби хезмәт вазифаларын (хезмәт вазифаларын)

башкару белән бәйле имгәнү яки авыру булмау фактын ачыклау һәм дәлилләү бурычы хәрби табиблар комиссияләренә йөкләнгән, аларның бәяләмәләре өстеннән судта шикаять итү мөмкин.

(03.12.2007 нән 319-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

**Маддә 22. Пенсия күләме**

Әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән затларга инвалидлык буенча пенсия түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

а) хәрби яралану аркасында I һәм II төркем инвалидларына – әлеге Канунның 43 маддәсендә каралган акчалата тәэмин итүнең тиешле суммаларының 85 проценты, III төркем инвалидларына – 50 проценты;

б) хәрби хезмәт вакытында барлыкка килгән авыру аркасында I һәм II төркем инвалидларына – әлеге Канунның 43 маддәсендә каралган акчалата тәэмин итүнең тиешле суммаларының 75 проценты, III төркем инвалидларына – 40 проценты.

(04.11.2014 нән 342-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

**Маддә 23. Инвалидлык буенча пенсиянең минималь күләме**

(03.12.2007 нән 319-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

Әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән затларга билгеләнә торган инвалидлык буенча пенсия түбәндәге күрсәткечләрдән кимрәк була алмый:

а) хәрби яралану аркасында I һәм II төркем инвалидларына – әлеге Канунның 46 маддәсенең беренче өлешендә күрсәтелгән пенсиянең түләү күләменең 300 проценты, II төркем инвалидларына – 250 проценты, III төркем – 175 проценты;

б) хәрби хезмәт вакытында барлыкка килгән авыру аркасында I һәм II төркем инвалидларына –әлеге Канунның 46 маддәсенең беренче өлешендә күрсәтелгән пенсиянең түләү күләменең 250 проценты, II төркем инвалидларына – 200 проценты, III төркем – 150 проценты;

**Маддә 24. Инвалидлык буенча пенсиягә өстәмәләр**

(03.12.2007 нән 319-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

Әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән I төркем инвалидлары булган яки 80 яшькә җиткән затларга, шулай ук асрауларында әлеге Канунның 31, 33 һәм 34 маддәләрендә, 29 маддәнең өченче өлешенең "а", "б" һәм "г" пунктларында күрсәтелгән гаиләнең эшкә яраксыз әгъзалары торган I һәм II төркем эшләмәүче инвалидларына аларга билгеләнә торган инвалидлык буенча пенсиясегә (шул исәптән минималь күләмдә исәпләнгән пенсиягә) әлеге Канунның 17 маддәсенең беренче өлешенең "а "һәм" б " пунктларында каралган өстәмә түләүләр исәпләнә.

(24.07.2009 нән 213-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

Әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән затларга – "Ветераннар турында" Федераль канунның 2 маддәсенең 1 пунктының "а"- "ж" һәм "и" пунктчаларында күрсәтелгән затлар арасыннан Бөек Ватан сугышында катнашучыларга аларга билгеләнә торган инвалидлык буенча пенсиясегә (шул исәптән минималь күләмдә исәпләнгән пенсиягә) – әлеге канунның 46 маддәсенең беренче өлешендә күрсәтелгән пенсиянең исәпләү күләменең 32 проценты күләмендә өстәмә түләү исәпләнә, I төркем инвалидлары булган яки 80 яшькә җиткән затларга – исәпләү күләменең 64 проценты күләмендә өстәмә түләү исәпләнә.

Әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән хәрби яралану аркасында инвалид булган затларга алар 60 һәм 55 яшькә җиткәннән соң (тиешеенчә ир-атларга һәм хатын-кызларга) аларга билгеләнә торган инвалидлык буенча пенсиясегә (шул исәптән минималь күләмдә исәпләнгән пенсиягә) – әлеге канунның 46 маддәсенең беренче өлешендә күрсәтелгән пенсиянең исәпләү күләменең 100 проценты күләмендә өстәмә түләү исәпләнә.

(Өченче өлеш 12.11.2012 нән 181-ФЗ номерлы Федераль канун тарафыннан кертелгән)

**Маддә 25. Инвалидлык буенча пенсия билгеләнә торган чор**

Әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән затларга инвалидлык буенча пенсия медицина-социаль экспертиза федераль оешмалары тарафыннан билгеләнгән инвалидлык чорына билгеләнә, ә инвалидлар булган 60 яшьтән өлкәнрәк ир-атларга һәм инвалидлар булган 55 яшьтән өлкәнрәк хатын-кызларга – бары тик аларның гаризасы буенча аларны яңадан таныклау белән гомерлеккә билгеләнә.

(03.12.2007 нән 319-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

Әлеге маддәдә күрсәтелгән яшькә җитмәгән пенсионер хезмәткә яраклы дип танылган очракта аңа пенсия ул хезмәткә яраклы дип танылган ай азагына кадәр түләнә, ләкин инвалидлыгы билгеләнгән көнненнән дә артып түләнми.

**Маддә 26. Инвалидлык төркемен яңадан тикшеогәндә пенсия күләмен үзгәртү**

Инвалидлык төркеме яңадан тикшерелгәндә пенсия күләме дә үзгәрә. Хәрби яралану аркасында инвалидның инвалидлыгы гомуми авыру, хезмәт имгәнүе яки профессиональ авыру сәбәпле көчәйсә, пенсия, аның элекке сәбәпләрен саклап калып, яңа инвалидлык төркеме буенча исәпләнә.

**Маддә 27. Яңадан таныклау срогын үткәреп җибәрү очрагында пенсия түләүен туктатып тору һәм яңарту**

Әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән затлар арасыннан инвалид медицина-социаль экспертиза федераль оешмаларында яңадан таныклау срогын үткәреп җибәрсә, пенсияне түләү инвалидлыгы билгеләнгән көннән туктатыла, ә аны яңадан инвалид дип таныган очракта пенсия инвалид дип таныган көннән яңадан билгеләнә.

(03.12.2007 нән 319-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

Инвалид яңадан таныклау срогын нигезле сәбәп аркасында үткәреп җибәрсә һәм медицина-социаль экспертиза федераль оешмалары тарафыннан үткән вакыт

өчен инвалид дип танылса, пенсияне түләү инвалид дип танылган көннән яңадан гамәлгә ашырыла. Әгәр дә яңадан таныклау вакытында аңа инвалидлыкның башка төркеме (югарырак яки түбәнрәк) билгеләнгән булса, яңадан таныклау көненә кадәр үткән вакыт өчен пенсия алдагы инвалидлык төркеме буенча түләнә.

(03.12.2007 нән 319-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

## Бүлек IV. ТУЕНДЫРУЧЫСЫН ЮГАЛТУ ОЧРАГЫ БУЕНЧА ПЕНСИЯ

### Маддә 28. Туендыручысын югалту очрагы буенча пенсия хокукын билгели торган шартлар

Әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән затларның гаиләләренә туендыручысын югалту очрагы буенча пенсия, әгәр туендыручысы хезмәт иткән вакытта яисә хезмәттән азат ителгән көннән өч айдан да соңга калмыйча үлгән (һәлак булган) булса, яисә шул сроктан соң үлгән (һәлак булган) очракта да хезмәт иткән чорда барлыкка килгән контузия, имнәнү яки авыру нәтиҗәсендә үлсә, ә шушы затлар арасыннан пенсионерларның гаиләләренә – әгәр дә туендыручылары пенсия алу вакытында үлсә яки аңа пенсия түләүен туктатканнан соң биш елдан да соңга калмыйча үлсә, билгеләнә. Шул ук вакытта әсирлектә булганда үлгән элекке хәрби хезмәткәрләрнең гаиләләре (әлеге Канунның 18 маддәсенең беренче өлешендә күрсәтелгән шартларны үтәгәндә) һәм хәрби гамәлләр чорында хәбәрсез югалган хәрби хезмәткәрләрнең гаиләләре фронтта һәлак булучыларның гаиләләренә тиңләштерелә.

### Маддә 29. Пенсиягә хокуклы гаилә әгъзалары

Туендыручысын югалту очрагы буенча пенсиягә әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән үлгән (һәлак булган) затлар гаиләсенең эшкә яраксыз әгъзалары хокуклы.

Туендыручының асравында торуга карамастан пенсия киләселәргә билгеләнә: хезмәткә яраксыз балаларга; хезмәткә яраксыз ата-аналарга һәм ирегә (хатынга), әгәр алар туендыручысы үлгәннән соң яшәү өчен акча чыганагын югалтсалар; әлеге

Канунның 21 маддәсенең "а" пунктында күрсәтелгән сәбәпләр аркасында үлгән затларның эшкә яраксыз ата-аналарына һәм ирләренә (хатыннарына); әлеге маддәнең "в" пунктында күрсәтелгән гаиләнең башка әгъзасына.

Гаиләнең эшкә яраксыз әгъзалары булып киләселәр санала:

а) белем бирү оешмаларында көндезге формада белем алучы (Рәсәй Федерациясенең милли гвардиясе гаскәрләренә яки эчке эшләр органнарына хәрби хезмәткә, хезмәткә керүгә бәйле белем бирү оешмаларыннан тыш) 18 яшькә җитмәгән балалар, абыйлар, сеңелләр һәм оныклар яки ул яшькә җиткән, тик 18 яшькә җиткәнче инвалид булганнар – укуларын тәмамлауга кадәр, тик 23 яшьтән дә узмыйча. Абыйлар, апалар һәм оныклар, эшкә яраклы ата-аналары булмаса, пенсиягә хокуклы;

(02.07.2013 нән 185-ФЗ номерлы, 01.07.2017 нән 154-ФЗ номерлы федераль кануннар редакциясендә)

б) әтисе, әнисе һәм ире (хатыны), әгәр дә алар: ир-атлар – 60 яшькә җитсә, хатын-кызлар – 55 яшькә, җитсә, яки инвалидлар булсалар;

в) яшькә һәм эшкә яраксызлыкка карамастан ире (хатыны) яки ата-аналардан берсе, яки бабае, әбие, абыйсы яки апасы, әгәр ул үлгән туендыручының 14 яшькә җитмәгән балаларын, абыйларын, апаларын яки оныкларын караса һәм эшләмәсә;

г) бабае һәм әбие – аларны канун буенча карарга тиеш затлар булмаган очракта.

**Маддә 30. Ташламалы шартларда пенсиягә хокук**

(01.06.1999 нән 110-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

Әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән затларның әлеге Канунның 21 маддәсенең "а" пунктында санап кителгән сәбәпләр аркасында үлгән затларның ире (хатыны) 55 һәм 50 (тиешенчә ир-атларга һәм хатын-кызларга) яшькә җиткәч туендыручысын югалту очрагы буенча пенсиягә хокуклы, ә аларның санынннан

үлгәннең 8 яшькә җитмәгән баласын караучылары яшькә, эшкә яраксызлыкка, эшләүгә яки эшләмәүгә карамастан, шул исәптән эчке эшләр органнарында, Янгынга каршы дәүләт хезмәтендә, җинаять-башкарма системасы оешмаларында һәм органнарында, Рәсәй Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләрендә хәрби хезмәт итүгә, хезмәт итүгә карамастан күрсәтелгән пенсиягә хокуклы.

(30.12.2006 нән 272-ФЗ номерлы), 08.05.2008 нан 64-ФЗ номерлы, 03.07.2016 нән 227 номерлы, 03.07.2016 нән 305-ФЗ номерлы, 01.07.2017 нән 154-ФЗ номерлы федераль кануннар редакциясендә)

Әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән әлеге Канунның 21 маддәсенең "а" пунктында санап үтелгән сәбәпләр аркасында үлгән (һәлак булган) затларның ата-аналары (күрсәтелгән затларның үлеме аларның хокукка каршы гамәлләре нәтиҗәсендә килеп чыкан очраклардан тыш) үлгәнннең (һәлак булганның) асравында торуга, тормауга карамастан туендыручысын югалту очрагы буенча пенсиягә 55 һәм 50 яшькә җиткәч (тиешенчә ир-атларга һәм хатын-кызларга) хокуклы. Шул ук вакытта пенсия ата - аналарның һәрберсенә әлеге Канунда каралган күләмдә билгеләнә.

**Маддә 31. Асрама булып саналучы үлгәннәрнең гаилә әгъзалары**

Әгәр дә үлгәннең гаилә әгъзалары аның тулы асравында торсалар яки ул алар өчен яшәү өчен даими һәм төп акча чыганагы булган ярдәм күрсәтсә, мондый гаилә әгъзалары аның асравында дип санала.

Алар өчен яшәү өчен даими һәм төп акча чыганагы булган ярдәм күрсәткән үлгәннең гаилә әгъзаларына, алар үзләре нинди дә булса пенсия алсалар, туендыручысын югалту очрагы буенча пенсия билгеләнә ала.

**Маддә 32. Үз көчен югалткан. - 03.12.2007 нән 319-ФЗ номерлы Федераль канун.**

**Маддә 33. Уллыкка алучыларның һәм уллыкка алынганнарның пенсиягә хокукы**

Уллыкка алучылар туендыручысын югалту очрагы буенча пенсиягә ата-аналар белән беррәттән, ә уллыкка алынганнар – үги ата-ананың үз балалары белән беррәттән хокуклы.

Туендыручысын югалту очрагы буенча пенсиягә хокуклары булган балигъ булмаганнар бу хокукны уллыкка алынган очракта да саклап кала.

**Маддә 34.Үги атаның, үги ананың, үги кызның, үги малайның пенсиягә хокуклары**

Үги ата һәм үги ана туендыручысын югалту очрагы буенча пенсиягә ата-аналар белән беррәттән хокуклы, әгәр дә алар үлгән үги малайны яки үлгән үги кызны биш елдан да ким түгел тәрбияләгән булсалар.

Үги малай һәм үги кыз туендыручысын югалту очрагы буенча пенсиягә үги ата-ананың үз балалары белән беррәттән хокуклы.

**Маддә 35. Яңадан өйләнгәндә (кияүгә чыкканда) пенсияне саклау**

Үлгәннең иренә (хатынына) билгеләнгән туендыручысын югалту очрагы буенча пенсия яңадан өйләнгәндә (кияүгә чыкканда) дә саклана.

**Маддә 36. Пенсия күләме**

Туендыручысын югалту очрагы буенча пенсия түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

а) әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән әлеге Канунның 21 маддәсенең "а" пунктында санап кителгән сәбәпләр аркасында үлгән затларның гаиләләренә – әлеге Канунның 43 маддәсендә каралган туендыручының акчалата тәэмин итүенең тиешле суммасының 50 проценты гаиләнең эшкә яраксыз һәр әгъзасына туры килә. Шул ук норма буенча туендыручының үлүе сәбәпләренә карамастан үлү көненә хәрби яралану аркасында инвалид булган пенсионерларның гаиләләренә, ике ата-ананы да югалткан балаларга, үлгән ялгыз ананың балаларына пенсия билгеләнә.

(28.11.1995 нән 186-ФЗ номерлы, 04.11.2014 нән 342-ФЗ номерлы федераль кануннар редакциясендә)

б) әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән әлеге Канунның 21 маддәсенең "б" пунктында санап кителгән сәбәпләр аркасында үлгән затларның гаиләләренә – әлеге Канунның 43 маддәсендә каралган туендыручының акчалата тәэмин итүенең тиешле суммаларының 40 проценты гаиләнең эшкә яраксыз һәр әгъзасына бирелә.

(04.11.2014 нән 342-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

**Маддә 37. Туендыручысын югалту очрагы буенча пенсиянең минималь күләме**

(03.12.2007 нән 319-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

Туендыручысын югалту очрагы буенча пенсия әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән затлар гаиләләренә һәм әлеге затлар арасыннан үлгән пенсионерларның гаиләләренә пенсия киләсе күрсәткечләрдән түбәнрәк була алмый:

а) әлеге канунның 36 маддәсенең "а" пункты нигезендә пенсияне исәпләгәндә – әлеге Канунның 46 маддәсенең беренче өлешендә күрсәтелгән пенсиянең исәпләү күләменең 200 проценты аны алу хокукына ия булган һәр гаилә әгъзасына;

б) әлеге канунның 36 маддәсенең "б" пункты нигезендә пенсияне исәпләгәндә – әлеге Канунның 46 маддәсенең беренче өлешендә күрсәтелгән пенсиянең исәпләү күләменең 150 проценты аны алу хокукына ия булган һәр гаилә әгъзасына;

**Маддә 38. Туендыручысын югалту очрагы буенча пенсиягә өстәмәләр**

(03.12.2007 нән 319-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

I төркем инвалид булган яки 80 яшькә җиткән гаилә әгъзаларына туендыручысын югалту очрагы буенча билгеләнгән пенсиягә (шул исәптән минималь күләмдә исәпләнгән пенсиягә) аларны карау өчен әлеге Канунның 17 маддәсенең беренче өлешенең "а" пунктында каралган күләмдә өстәмә исәпләнә.

(24.07.2009 нән 213-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

Ата-анасын югалткан балачактан I һәм II төркем инвалидларына һәм инвалид-балаларга яки үлгән ялгыз анадан калган күрсәтелгән балаларга билгеләнә торган туендыручысын югалту очрагы буенча пенсиягә (шул исәптән минималь күләмдә исәпләнгән пенсиягә) – әлеге Канунның 46 маддәсенең беренче өлешендә күрсәтелгән пенсиянең исәпләү күләменең 32 проценты күләмендә өстәмә исәпләнә.

Әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән затлар арасыннан (күрсәтелгән затларның үлеме хокукка каршы гамәлләре нәтиҗәсендә килеп туган очраклардан тыш) әлеге Канунның 21 маддәсенең "а" пунктында санап кителгән сәбәпләр аркасында ике һәм аннан күбрәк туендыручысын (ирен (хатынын) һәм (яисә) балаларын) югалткан затларга (күрсәтелгән затларның үлеме аларның хокукка каршы гамәлләре нәтиҗәсендә килеп чыкан очраклардан тыш) күрсәтелгән туендыручыларның һәрберсенең үлүе (һәлак булуы) сәбәпле (аларга туендыручысын югалту очрагы буенча пенсия билгеләнгән туендыручыдан тыш) әлеге Канунның 46 маддәсенең беренче өлешендә күрсәтелгән пенсиянең исәпләү күләменең 200 проценты күләмендә өстәмә исәпләнә.

(Өченче өлеш 01.05.2017 нан 95-ФЗ номерлы Федераль канун тарафыннан кертелгән)

18 яшькә җитмәгән белем бирү оешмаларында (Рәсәй Федерациясенең милли гвардиясе гаскәрләренә яки эчке эшләр органнарына хәрби хезмәткә, хезмәткә керүгә бәйле белем бирү оешмаларыннан тыш) көндезге формада белем алучы балаларга – укуларын тәмамлауга кадәр, тик 23 яшьтән дә узмыйча һәм балачактан I һәм II төркем инвалидлары булган әлеге Канунның 21 маддәсенең "а" пунктында китерелгән сәбәпләр аркасында әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән затлар арасыннан ата-анасын югалткан балаларга (күрсәтелгән затларның үлеме хокукка каршы гамәлләре нәтиҗәсендә барлыкка килгән очраклардан тыш) аларга ата-ананың берсе улүе (һәлак булуы) сәбәпле билгеләнгән туендыручысын югалту очрагы буенча пенсиягә (шул исәптән минималь күләмдә исәпләнгән пенсиягә) ата-

ананың берсе үлеме (һәлак булуы) сәбәпле әлеге Канунның 46 маддәсенең беренче өлешендә күрсәтелгән пенсиянең исәпләү күләменең 200 проценты күләмендә өстәмә исәпләнә.

(дүртенче өлеш 01.05.2017 нан 95-ФЗ номерлы Федераль канун тарафыннан кертелгән)

Әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән бер үк вакытта әлеге маддәнең икенче һәм дүртенче өлешләрендә каралган өстәмә түләүләрне исәпләү хокукына ия булган затларның балаларына иң зур күләмдә булган бер өстәмә түләү исәпләнә.

(бишенче өлеш 01.05.2017 нан 95-ФЗ номерлы Федераль канун тарафыннан кертелгән)

Туендыручысын югалту очрагы буенча пенсиягә әлеге маддәнең өченче һәм дүртенче өлешләрендә каралган өстәмәләр туендыручысын югалту очрагы буенча пенсия билгеләүче федераль башкарма хакимият органнары яисә федераль дәүләт органнары тарафыннан исәпләнә.

(алтынчы өлеш 01.05.2017 нан 95-ФЗ номерлы Федераль канун тарафыннан кертелгән)

**Маддә 39. Пенсия билгеләнә торган чор**

Туендыручысын югалту очрагы буенча пенсия әлеге Канунның 29 маддәсенең нигезендә үлгәннең хезмәткә яраксыз дип саналган гаилә әгъзасына тулы чорга билгеләнә, ә гаилә әгъзаларыннан булган 60 яшькә җиткән ир-атларга, 55 яшькә җиткән хатын-кызларга – гомерлеккә билгеләнә.

**Маддә 40. Пенсия өлешен чыгару**

Гаилә әгъзасы гаризасы буенча туендыручысын югалту очрагы буенча пенсия өлеше аерым чыгарыла һәм түләнә. Пенсия өлешен чыгару әлеге Канунда каралган пенсияне аның чыгаруы артыннан мөрәҗәгать иткән гаилә әгъзасы өчен исәпләү нормаларын исәпкә алып башкарыла.

Пенсия өлешен чыгару турында гариза тәкъдим ителгән айдан соң килүче айның беренче числосыннан башкарыла.

**Маддә 41. Пенсиягә хокукны югалтканда пенсия түләүенең туктатылуы**

Әгәр туендыручысын югалту очрагы буенча пенсия билгеләнгән гаилә составында үзгәрешләр булса, аның нәтиҗәсендә гаиләнең аерым әгъзалары яки тулаем алганда гаилә пенсия хокукын югалтса, бу үзгәреш булган айдан соң килүче айның беренче числосыннан пенсия күләме киметелә яки аны түләү туктатыла.

**Маддә 42. Үлгәннең гаилә әгъзаларына инвалидлык билгеләү тәртибе һәм сроклары**

Инвалид булган гаилә әгъзаларына әлеге канунның 20, 25 һәм 27 маддәләрендә каралган медицина-социаль экспертиза федераль оешмаларында тикшерүдә тәнәфес булганда инвалидлыкны билгеләү һәм пенсияне түләү тәртибе һәм сроклары турында кагыйдәләр кагыла.

(03.12.2007 нән 319-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

## V Бүлек. ПЕНСИЯЛӘРНЕ ИСӘПЛӘҮ

**Маддә 43. Пенсияләрне исәпләү өчен акчалата тәэмин итү**

Әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән затларга һәм аларның гаиләләренә билгеләнә торган пенсияләр эчке эшләр органнарында, Янгынга каршы дәүләт хезмәтендә наркотик дарулар һәм психотроп матдәләр әйләнешен контрольдә тоту органнарында хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләрнең, гади һәм җитәкче составыннан затларның акчалата тәэмин итүеннән, җинаять-башкарма оешмаларында һәм органнарында, Рәсәй Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләрендә хезмәт итүче затларның акчалата тәэмин итүеннән исәпләнә.

Аларга пенсияне исәпләү өчен Рәсәй Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә хәрби вазифа буенча оклад яки хезмәттәге оклад, хәрби исем яки махсус исем буенча оклад, хезмәт яисә вазыйфаи оклад (ерак, биектау җирлекләрендә һәм башка махсус шартларда хезмәт иткән өчен окладларны

арттырмыйча) һәм тиешле еллар эшләгән (хезмәт стажы) өчен айлык өстәмә яки процент өстәмә акчалата тәэмин итү индексациясе сәбәпле түләүне кертеп исәпкә алына.

(28.11.1995 нән 186-ФЗ номерлы, 21.07.1998 нән 117-ФЗ номерлы, 30.06.2003 нән 86-ФЗ номерлы, 25.07.2002 нән 116-ФЗ номерлы, 01.12.2007 нән 311-ФЗ номерлы, 08.11.2011 нән 309-ФЗ номерлы, 03.07.2016 нән 227-ФЗ номерлы, 01.07.2017 нән 154-ФЗ номерлы Федераль кануннар редакциясендә)

Әлеге акчалата тәэмин итү 2012 елның 1 гыйнварыннан 54 процент күләмендә пенсия исәпләнгәндә исәпкә алына һәм 2013 елның 1 гыйнварыннан башлап ел саен 2 процентка 100 процентка җиткәнче арта. Инфляция (сатып алу бәяләре) дәрәҗәсен исәпкә алып чираттагы финанс елына һәм план чорына федераль бюджет турында Федераль канун нигезендә күрсәтелгән ел саен арту чираттагы финанс елына һәм план чорына 2 процентттан артып киткән күләмдә билгеләнергә мөмкин.

(икенче өлеш 08.11.2011 нән 309-ФЗ номерлы Федераль канун тарафынна кертелгән)

**Маддә 44. Пенсионерлар гаиләләренә пенсияне исәпләү**

Әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән затлар арасыннан пенсионерларның гаиләләренә туендыручысын югалту очрагы буенча пенсия пенсиясе исәпләнгән (яңадан исәпләнгән) яки яңадан исәпләнергә тиеш булган туендыручының акчалата тәэмин итүеннән исәпләнә.

**Маддә 45. Пенсионерларның кайбер категорияләренә пенсияләрне арттыру**

(03.12.2007 нән 319-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

Әлеге Канун нигезендә билгеләнә торган тиешле еллар эшләгән өчен, инвалидлык һәм туендыручысын югалту очрагы буенча пенсияләр (шул исәптән минималь күләмдә исәпләнгән) киләселәргә арта:

а) Советлар Союзы Геройларына, Рәсәй Федерациясе Геройларына һәм өч дәрәҗәдәге Дан ордены белән бүләкләнгән затларга – пенсия күләменең 100 процентына, Социалистик Хезмәт Геройларына, Рәсәй Федерациясе Хезмәт Геройларына – пенсия күләменең 50 процентына. Шул ук вакытта Советлар Союзы Герое, Рәсәй Федерациясе Герое, Социалистик Хезмәт Герое яки Рәсәй Федерациясе Хезмәт Герое исеменә күп тапкырлар лаек булган затларга пенсия күрсәтелгән тәртиптә һәр алынган исем буенча арта;

(28.12.2013 нән 397-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

б) Олимпия уеннары чемпионнарына, Паралимпия уеннары чемпионнарына, Сурдлимпия уеннары чемпионнарына – пенсия күләменең 50 процентына арта;

(09.11.2009 нән 253-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә))

в) өч дәрәҗәдәге Хезмәт Даны ордены яки "ССҖБ Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт өчен" ордены белән бүләкләнгән затларга – пенсия күләменең 15 процентына арта;

г) "Ветераннар турында" Федераль канунының 2 маддәсенең 1 пунктының "а" – "ж" һәм "и" пунктчаларында күрсәтелгән затлар саныннан Бөек Ватын сугышының катнашучыларына, шулай ук "Ветераннар турында" Федераль канунының 3 маддәсенең 1 пунктының 1-4 пунктачаларында күрсәтелгән затлар саныннан хәрби гамәлләр ветераннарына – әлеге канунның 46 маддәсенең беренче өлешендә күрсәтелгән пенсиянең исәпләү күләменең 32 процентына арта;

д) 1941 елның 22 июненнән 1945 елның 3 сентябренә кадәр хәрби хезмәттә кимендә алты ай булган затларга (гамәлдәге армия составында булган затлардан тыш), шулай ук Бөек Ватан сугышы чорында (1941 елның 22 июненнән 1945 елның 9 маена кадәр) кимендә алты ай эшләгән яисә Бөек Ватан сугышы елларында фидакарь хезмәт өчен ССҖБ орденнары һәм медальләре белән бүләкләнгән затларга (ССҖБнең вакытлыча оккупацияләнгән территорияләрендә эшләү вакытын кертмичә) – әлеге канунның 46 маддәсенең беренче өлешендә күрсәтелгән пенсиянең исәпләү күләменең 16 процентына арта. Шул ук вакытта 1931 елның 31

декабренә (датаны исәпкә алып) кадәр туган затларга әлеге пункт нигезендә пенсияләр 1941 елның 22 июненнән 1945 елның 3 сентябренә кадәр чорда хәрби хезмәт итүен яисә Бөек Ватан сугышы чорында эш стажын раслый торган документлардан башка арттырыла;

е) икенче бөтендөнья сугышы чорында немец фашистлары һәм аларның союздашлары тарафыннан корылган фашист концлагерьларының, гетто һәм башка мәҗбүри тоту урыннарының балигъ булмаган элекке тоткыннарына – әлеге канунның 46 маддәсенең беренче өлешендә күрсәтелгән пенсиянең исәпләү күләменең 32 процентына арта.

ж) сәяси мотивлар буенча нигезсез репрессияләнгән һәм соңыннан реабилитацияләнгән затларга – әлеге Канунның 46 маддәсенең беренче өлешендә күрсәтелгән пенсиянең исәпләү күләменең – 16 процентына арта.

з) "Блокадалы Ленинградта яшәүче" билгесе белән бүләкләнгән затларга – әлеге Канунның 46 маддәсенең беренче өлешендә күрсәтелгән пенсиянең исәпләү күләменең 32 процентына арта. Күрсәтелгән арттыру әлеге Канунның 16 маддәсенең "в" пунктында каралган арттыру белән исәпләнгән пенсияләргә билгеләнми;

(13.02.2008 нән 3-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

и) Бөек Ватан сугышы чорында хәрби гамәлләр яисә аларның нәтиҗәләре сәбәпле яралану,контузия яки имгәнүләр аркасында балачактан инвалидларга – әлеге Канунның 46 маддәсенең беренче өлешендә күрсәтелгән пенсиянең исәпләү күләменең – 32 процентына арта.

Әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән затларга һәм 2002 елның 4 мартыннан 21-ФЗ номерлы "Рәсәй Федерациясе алдында күренекле казанышлары һәм аерым күрсәткән хезмәтләре өчен Рәсәй Федерациясе гражданнарын өстәмә айлык матди тәэмин итү турында" Федераль канун тарафыннан билгеләнгән өстәмә айлык матди тәэмин итүне алучы әлеге затларның гаилә әгъзаларына әлеге маддәнең беренче өлешенең "а"  - "в" пунктлары  нигезендә артмый.

**Маддә 46. Пенсиянең исәпләү күләме һәм пенсияләргә өстәмә түләүләрне исәпләү, пенсияләрне зурайту һәм арттыру кагыйдәләре**

(03.12.2007 нән 319-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

Пенсияләрнең минималь күләме әлеге Канунда каралган пенсияләрне зурайту һәм арттыру пенсиянең исәпләү күләменнән чыгып билгеләнә, ул күләм "Рәсәй Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында" Федераль канунының 18 маддәнең 1 пунктының 1 пунктчасында каралган социаль пенсия күләменнән чыгып билгеләнә һәм күрсәтелгән социаль пенсиянең күләме үзгәрүе (индексациясе) белән беррәттән яңадан тикшерелә.

(24.07.2009 нән 213-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

Гаиләдә әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән затлар арасыннан ике һәм аннан күбрәк асравында гаиләнең бер үк эшкә яраксыз әгъзасы булучы пенсионер торса, әлеге Канунның 17 маддәсенең беренче өлешенең "б" пунктында яисә 24 маддәсенең беренче өлешендә каралган өстәмә пенсиягә аларның теләге буенча күрсәтелгән пенсионерларның берсенә генә исәпләнә.

Әлеге Канунның 45 маддәсенең беренче өлешенең "а" - "в" пунктларында каралган пенсияләрне арттыру әлеге Канунның 45 маддәсенең "г" -"и" пунктларында каралган арттыруларсыз, өстәмә түләүләрсез, зурайтуларсыз исәпләнгән пенсияләргә билгеләнә.

Бер үк вакытта әлеге Канунның 45 маддәсенең беренче өлешенең "г", "д" һәм "з" пунктларында каралган пенсияләрне берничә тапкыр арттыру хокукы булганда, пенсиягә күләме буенча иң күп арттыру билгеләнә.

Туендыручысын югалту очрагы буенча пенсия гаиләнең эшкә яраксыз берничә әгъзасына билгеләгәндә әлеге Канунның 45 маддәсендә каралган пенсияләрне арттырулар тиешле арттыруларга хокуклы булган гаиләнең һәр әгъзасына тиешле туендыручысын югалту очрагы буенча пенсиягә билгеләнә.

Әлеге Канунның 7 маддәсе нигезендә бер үк вакытта ике пенсия алуга хокуклы булган очракта өстәмә түләүләр һәм арттырулар тиешенчә бер пенсиягә исәпләнә һәм билгеләнә.

**Маддә 47. Үз көчен югалтткан. - 13.02.2008 нән 3-ФЗ номерлы Федераль канун**

**Маддә 48. Пенсия күләменә карата коэффициентлар куллану**

(08.11.2011 нән 309-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

Эчке эшләр органнары, Янгынга каршы дәүләт хезмәте органнары, наркотик дарулар һәм психотроп матдәләр әйләнешен контрольдә тоту органнары, җинаять-башкарма оешмалары һәм органнар, Рәсәй Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләре хезмәткәрләренең һәм хәрби хезмәткәрләренең акчалата тәэмин итүенә ия булган Рәсәй Федерациясе канунчылыгы нигезендә коэффициентлар кулланылган җирлектә яшәүче әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән затлар арасыннан пенсионерларга һәм аларның гаилә әгъзаларына аларның бу урыннарында яшәү чорына әлеге канун нигезендә билгеләнә торган пенсияләр, әлеге канунның 17, 24 һәм 38 маддәләрендә каралган бу пенсияләргә өстәмәләр, әлеге Канунның 16 маддәсендә каралган зурайтулар әлеге федераль кануннар нигезләрендә Рәсәй Федерациясе Хөкүмәте хезмәткәрләре һәм хәрби хезмәткәрләре өчен әлеге җирлектә билгеләнгән тиешле коэффициентын кулланып исәпләнә.

(03.07.2016 нән 227-ФЗ номерлы, 01.07.2017 нән 154-ФЗ номерлы Федераль кануннар редакциясендә

Әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән Ерак Төньякта һәм аңа тиңләштерелгән җирлекләрдә тиешенчә кимендә 15 һәм 20 календарь ел хезмәт иткән пенсионерларга пенсия (әлеге Канунның 17 һәм 24 маддәләрендә каралган пенсияләргә өстәмәләр һәм әлеге Канунның 16 маддәсендә каралган зурайтуларны кертеп) әлеге маддәнең беренче өлешен кулланып әлеге районнардан һәм җирлекләрдән яңа даими яшәү урынына чыкканда Рәсәй Федерациясе Хөкүмәте

тарафыннан билгеләнә торган тиешле коэффициентны исәпкә алып исәпләнгән пенсия күләме сакланып кала.

Әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән затлар арасыннан Ерак Төньякта һәм аңа тиңләштерелгән җирлекләрдә тиешенчә кимендә 15 һәм 20 календарь ел хезмәт иткән хәрби хезмәткәрләрнең һәм хезмәткәрләрнең акчалата тәэмин итүенә коэффициент билгеләнмәгән яки Ерак Төньякта һәм аңа тиңләштерелгән җирлекләрдә соңгы эш урыны буенча әзрәк күләмдә билгеләнгән җирлектә яшәүче пенсионерларга әлеге Канун нигезендә билгеләнгән пенсияләр (әлеге Канунның 17 һәм 24 маддәләрендә каралган пенсияләргә өстәмәләрне һәм әлеге Канунның 16 маддәсендә каралган зурайтуларны кертеп) Ерак Төньякта һәм аңа тиңләштерелгән җирлекләрдә соңгы эш урыны буенча хезмәткәрләрнең һәм хезмәткәрләрнең акчалата тәэмин итүенә билгеләнгән коэффициентны кулланып пенсияне билгеләү артыннан мөрәҗәгать итү вакытына карамастан исәпләнә. Шул ук вакытта күрсәтелгән пенсияләрне исәпләгәндә исәпкә алына торган коэффициентның чик күләме 1,5 тәшкил итә.

**Маддә 49. Пенсияләрне, пенсияләрнең минималь күләмен, пенсияләргә өстәмә түләүләрне, пенсияләрне арттыруны һәм зурайтуны яңадан карап тикшерү**

(03.12.2007 нән 319-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

Әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән затларга һәм аларның гаиләләренә билгеләнгән пенсияләр киләсе очракларда яңадан карап тикшерелергә тиеш:

а) хәрби хезмәткәрләрнең һәм хезмәткәрләрнең тиешле категорияләренең акчалата тәэмин итүен бер үк вакытта пенсия исәпләп чыгарганда исәпкә алына торган акчалата тәэмин итү дәрәҗәсеннән чыгып арттырганда;

б) һәр елның 1 гыйнварыннан башлап әлеге Канунның 43 маддәсенең икенче өлешендә билгеләнгән акчалата тәэмин итүне арттыруны исәпкә алып.

(беренче өлеш 08.11.2011 нән 309-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

Әлеге Канунда каралган пенсияләрнең минималь күләме, пенсияләргә өстәмәләр, пенсиянең зурайтулары, арттырулары әлеге Канунның 46 маддәсенең беренче өлешендә күрсәтелгән пенсиянең исәпләү күләмен арттырганда күрсәтелгән пенсиянең исәпләү күләмен арттыру белән бергә яңадан карап тикшерелергә тиеш.

Пенсияләрнең минималь күләме, пенсияләргә өстәмәләр, пенсиянең зурайтулары, арттырулары әлеге маддәдә күрсәтелгән нигезләрнең теләсә кайсы нигез барлыкка килгәндә, шул исәптән бер үк вакытта барлыкка килгәндә яңадан карап тикшерелергә тиеш.

## Бүлек VI. ПЕНСИЯНЕ БИЛГЕЛӘҮҺӘМ ТҮЛӘҮ

### Маддә 50. Пенсия белән тәэмин итү эшен оештыру

Әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән затларны һәм аларның гаиләләрен пенсия белән тәэмин итү эше Рәсәй Федерациясе Оборона министрлыгы, Рәсәй Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы, Җәзаларны үтәтү федераль хезмәте, Рәсәй Федерациясе Федераль иминлек хезмәте, Рәсәй Федерациясе Генераль прокуратурасы һәм Рәсәй Федерациясе Тикшерү комитеты тарафыннан халыкны социаль яклау органнары өчен билгеләнгән кануннар чыгаручы һәм башка норматив актлар тарафыннан пенсияләрне билгеләү һәм түләү тәртибенә карата гамәлгә ашырыла.

(28.11.1995 нән 186-ФЗ номерлы, 21.07.1998 нән 117-ФЗ номерлы, 29.06.2004 нән 58-ФЗ номерлы, 04.06.2014 нән 145-ФЗ номерлы, 03.07.2016 нән номерлы Федераль кануннар редакциясендә)

### Маддә 51. Пенсияне билгеләү артыннан мөрәҗәгать итү

Әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән затлар һәм аларның гаилә әгъзалары (2 маддәнең икенче өлешендә күрсәтелгәннәрдән тыш) пенсияләрне билгеләү турында гаризалар белән Рәсәй Федерациясе Оборона министрлыгының, Рәсәй Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының, Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең, Рәсәй Федерациясе Федераль иминлек хезмәтенең, Рәсәй Федерациясе

Генераль прокуратурасының һәм Рәсәй Федерациясе Тикшерү комитетының пенсия органнарына мөрәҗәгать итәләр.

(икенче өлеш 28.11.1995 нән 186-ФЗ номерлы, 21.07.1998 нән 117-ФЗ номерлы, 29.06.2004 нән 58-ФЗ номерлы, 04.06.2014 нән 145-ФЗ номерлы, 03.07.2016 нән 305-ФЗ номерлы Федераль кануннар редакциясендә)

Әлеге Канунның 2 маддәсендә күрсәтелгән затлар һәм аларның гаилә әгъзалары "Иминият пенсияләре турында" Федераль канун нигезендә пенсияне билгеләү турында гаризалар белән яшәү урыны буенча Рәсәй Федерациясе Пенсия фондының территориаль органнарына мөрәҗәгать итәләр.

(икенче өлеш 21.07.2014 нән 216-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

Пенсияләрне билгеләү турында гаризалар әлеге мәсьәләне хәл итү өчен кирәкле тиешле документлар белән бергә пенсия органнарына тапшырыла. Күрсәтелгән затлар пенсияне билгеләү өчен кирәкле документларны тапшырмаска хокуклы, әгәр дә мондый документлар (аларда булган мәгълүматлар) дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында яисә дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына буйсынган оешмаларда булса, мондый документлар 2010 елның 27 июленнән 210-ФЗ номерлы "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" Федераль канунының 7 маддәсенең 4 өлешендә билгеләнгән исемлеккә кертелмәгән булса. Мондый очракларда пенсия органы кирәкле документларны (аларда булган мәгълүматларны) башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына буйсынган оешмалардан Рәсәй Федерациесе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә сорый.

(01.07.2011 нән 169-ФЗ номерлы, 21.07.2014 нән 216-ФЗ номерлы Федераль кануннар редакциясендә)

**Маддә 52. Пенсияне билгеләү турында гаризаларны карау**

Гаризалар һәм алар белән бергә китерелгән документлар әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән затларга һәм аларның гаиләләренә пенсияне билгеләү

турында гариза тәкъдим ителгән көннән ун көннән дә соңга калмыйча яисә гариза биргәндә тапшырылмаган документлар тәкъдим ителгән көннән соң ун көннән дә соңга калмыйча карала, әгәр дә мондый документлар тапшыру бурычы мөрәҗәгать итүчегә йөкләнгән булса.

(01.07.2011 нән 169-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

**Маддә 53. Пенсияне билгеләү сроклары**

Әлеге канун нигезендә пенсияләр киләселәргә билгеләнә:

а) әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән затларга – хезмәттән азат ителгән көннән соң, ләкин эштән азат ителгәндә акчалата тәэмин итү түләнә торган соңгы көннән иртәрәк түгел, аларга соңрак сроклардан пенсия билгеләүнең түбәндәге очракларыннан тыш:

эштән азат ителгәннән өч ай үткәннән соң инвалидлык билгеләгәндә яки эштән азат ителгәннән соң килеп чыккан бәхетсезлек очрагы яки авыру нәтиҗәсендә инвалидлык билгеләгәндә – инвалидлык билгеләгән көннән алып;

абзац үз көчен югалткан. - 28.04.2009 нән 70-ФЗ номерлы Федераль канун;

б) әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән затлар гаиләләренә һәм әлеге затлар арасыннан пенсионерларга – туендыручыларының үлеме көненнән соң, ләкин акчалата тәэмин итү түләнә торган соңгы көннән иртәрәк түгел, аларга соңрак сроклардан пенсия билгеләүнең түбәндәге очракларыннан тыш:

пенсия яшенә ирешү яки инвалидлык билгеләү сәбәпле туендыручы үлеменнән соң пенсиягә хокуклы булган гаилә әгъзаларына – әлеге яшькә җитү яки инвалидлык билгеләү көненнән соң;

Яшәү өчен акча чыганагын югалту сәбәпле пенсиягә хокук алучы ата-аналарга, иргә (хатынга).

Үз вакытында мөрәҗәгать итмәү очрагында үткән вакыт өчен пенсия пенсиягә хокук алган көннән билгеләнә, ләкин аның артыннан мөрәҗәгать итү алыннан үткән 12 айдан артыграк түгел.

**Маддә 54. Пенсияне билгеләү артыннан мөрәҗәгать итү көне**

Пенсияне билгеләү артыннан мөрәҗәгать итү көне булып тиешле пенсия органына пенсияне билгеләү турында гариза белән тиешле документларны бирү көне санала, аларны тапшыру бурычы мөрәҗәгать итүчегә йөкләнсә, ә гариза һәм документларны почта буенча тапшырганда – аларны җибәрү датасы санала.

(беренче өлеш 01.07.2011 нән 169-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

Тапшыру бурычы йөкләнгән мөрәҗәгать итүче пенсияне билгеләү турында гаризага барлык кирәкле документлар да беркетелмәгән булса, мөрәҗәгать итүчегә кайсы документларны ул өстәмә рәвештә тапшырырга тиешлеге аңлатыла. Күрсәтелгән аңлатма алганнан соң өч ай үткәнче аларга әлеге документларны тапшырганда пенсия артыннан мөрәҗәгать итү көне булып гариза бирү көне яки әлеге маддәнең беренче өлешендә күрсәтелгән документларны почта буенча җибәрү датасы санала.

(01.07.2011 нән 169-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә

**Маддә 55. Билгеләнгән пенсияләр күләмнәрен яңадан исәпләү срогы**

(10.12.2010 нән 354-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

Әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән затларга һәм аларның гаилә әгъзаларына тиешле еллар эшләгән өчен, инвалидлык буенча, туендыручысын югалту очрагы буенча пенсия күләмен яңадан исәпләү киләсе очракларда башкарыла:

а) пенсия күләмен киметү ягына яңадан исәпләүгә китерә торган хәлләр барлыкка килгән айдан соң килүче айның беренче числосыннан;

б) пенсия күләмен арттыру ягына яңадан исәпләүгә китерә торган шартлар барлыкка килгән көннән соң.

Әгәр пенсионер пенсия күләмен арттыру ягына яңадан исәпләү хокукына ия булса, пенсиянең яңа һәм элекке күләмнәре арасындагы аерма аңа пенсия күләмен

яңадан исәпләү хокукын алган көннән соң түләнә башлый, ләкин пенсия күләмен яңадан исәпләү артыннын мөрәҗәгать итү көненә кадәрге 12 айдан да артмаска тиеш.

**Маддә 56. Пенсияләрне түләүнең гомуми тәртибе һәм аларны түләүче органнар**

(03.12.2007 нән 319-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

Әлеге Канунда каралган пенсияләрне түләү Рәсәй Федерациясе территориясе чикләрендә пенсионерларның яшәү урыны яки тору урыны буенча башкарма хакимиятнең федераль органнары һәм әлеге Канунның 11 маддәсендә күрсәтелгән федераль дәүләт органнарының пенсия органнары аша "Рәсәй Сбербанкы" ачык акционерлык җәмгыяте аша тиешле суммаларны кертемгә күчерү яки тиешле суммаларны федераль почта элемтәсе оешмалары аша күчерү юлы белән гамәлгә ашырыла.

(беренче өлеш 20.12.2017 нән 401-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

Рәсәй Федерациясе Хөкүмәте пенсия белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы башкарма хакимият федераль органнары яисә федераль дәүләт органнары тәкъдимнәре нигезендә күрсәтелгән түләүләрне гамәлгә ашыручы башка банкларны билгеләргә хокуклы, шул ук вакытта мондый һәр банк бер үк вакытта түбәндәге критерийларга туры килергә тиеш:

а) банкта хисап аеның беренче числосына 100 миллиард сумнан да ким булмаган күләмдә үз акчалары (капиталы) булырга тиеш;

б) банк Рәсәй Федерациясе яисә Рәсәй Федерациясе Үзәк банкы (Рәсәй банкы) контроле астында. Әлеге канун максатларында Рәсәй Федерациясе яисә Рәсәй Банкы контроле астында булу Рәсәй Федерациясе яисә Рәсәй Банкының турыдан-туры яисә читләтеп (юридик зат яки берничә юридик зат аша) тавышларның гомуми санының илледән артык проценты белән идарә итү юлы белән банк тарафыннан кабул ителә торган карарларны билгеләү, банкның устав капиталын тәшкил итүче тавыш бирүгә

хокук бирүче акциягә (өлешләргә) туры килә торган , бердәм башкарма органын һәм (яки) банкның күзәтчелек советы (директорлар советы) составының илледән артык процентын билгеләү (сайлау) мөмкинлеген аңлата.

в) банк дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрне файдалануга бәйле эшләр башкаруга лицензиягә ия булырга тиеш.

(икенче өлеш 20.12.2017 нән 401-ФЗ номерлы Федераль канун тарафынна кертелгән)

Пенсияне түләү тәртибе башкарма хакимиятнең федераль органнары, федераль дәүләт органнары һәм әлеге маддә нигезендә билгеләнгән банклар арасында төзелә торган килешүләр тарафыннан билгеләнә.

(икенче өлеш 20.12.2017 нән 401-ФЗ номерлы Федераль канун тарафынна кертелгән)

Тиешле суммаларны федераль почта элемтәсе оешмасы аша күчерү юлы белән әлеге Канунда каралган пенсияләрне түләү һәм пенсионерларның тору урыны яки яшәү урыны буенча пенсияләрне тапшыру әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән затларны һәм аларның гаиләләрен пенсия белән тәэмин итү өчен каралган федераль бюджет акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

Әлеге Канунда каралган пенсияләрне түләү агымдагы айда башкарыла.

Әлеге Канунда каралган пенсияләрне түләү башкарма хакимиятнең тиешле федераль органнары һәм федераль дәүләт органнары тарафыннан "Рәсәй Сбербанкы" ачык акционерлык җәмгыяте яки әлеге маддә нигезендә билгеләнгән башка банклар белән килешү нигезендә яисә федераль почта элемтәсе оешмалары тарафыннан билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

(өлеш 20.12.2017 нән 401-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

Өлеш 2018 елның 1 гыйнварыннан үз көчен югалткан. -20.12.2017 нән 401-ФЗ номерлы Федераль канун

Әлеге Канунда каралган пенсияләрне түләү тәртибе, шул исәптән тиешле дәүләт валютасында, әлеге Канунның 1 маддәсенең "б" пунктында күрсәтелгән затлар арасыннан Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлеге катнашучылары булмаган ССҖБнең элекке республикалары территориясендә яшәүче пенсионерларга һәм аларның гаиләләренә Рәсәй Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан әлеге дәүләтләр белән төзелгән килешүләрдән чыгып билгеләнә.

Пенсионер Рәсәй Федерациясе территориясе чикләрендә яңа яшәү урынына яки тору урынына күчкәндә аңа пенсияне түләү һәм тапшыру билгеләнгән тәртиптә теркәү органнары тарафыннан бирелгән пенсия эше һәм яшәү урыны буенча яки тору урыны буенча теркәлү турында документлар нигезендә аның яңа яшәү урыны яки тору урыны буенча гамәлгә ашырыла, әгәр пенсионерның Рәсәй Федерациясе территориясе чикләрендә яңа яшәү урыны яки яңа тору урыны буенча теркәү булмаса, аның пенсия эше буенча һәм яшәү урыны яки тору урыны күрсәтелгән шәхси гариза нигезендә гамәлгә ашырыла.

(07.06.2013 нән 127-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

Пенсионер теләге буенча пенсия Рәсәй Федерациясе канунчылыгында билгеләнгән тәртиптә бирелә торган ышаныч язуы буенча түләнә ала. Бер елдан артык гамәлдә булучы ышаныч язуы буенча пенсияне түләү пенсионер тарафыннан Рәсәй Федерациясе территориясе чикләрендә яшәү урыны яки тору урыны буенча теркәлүне ел саен раслау шарты белән ышаныч язуының гамәлдә булу срогы дәвамында башкарыла.

Әлеге маддә нигезендә пенсионер үлгәннән соң тиешле счетка күчерелгән пенсия суммалары федераль бюджетка кире кайтарылырга тиеш.

Әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән затлар пенсия органына тапшырыла торган пенсияне билгеләү һәм түләү турында гаризаларда булган белешмәләрнең дөрес булмавы өчен җаваплы.

Әгәр дөрес булмаган мәгълүматларны тәкъдим итү яки мәгълүматларны вакытында тәкъдим итмәү пенсияне түләү өчен акчаның артык чыгымына китергән

булса, гаепле затлар дәүләткә Рәсәй Федерациясе канунчылыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә китерелгән зыянны каплый.

(07.06.2013 нән 127-ФЗ номерлы Федераль канун тарафынна кертелгән)

**Маддә 57. Хезмәт хакы яки башка керем булганда пенсионерларга пенсияне түләү**

Әлеге Канун нигезендә билгеләнә торган пенсияләр пенсионерларда хезмәт хакы яки башка керем булуга карамастан тулысынча түләнә. Эшкә алынган пенсионерларга яки эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнүдән табыш алган пенсионерларга әлеге Канунның 17 маддәсенең "б" пунктында һәм 24 маддәсендә каралган пенсия өстәмәләре генә түләнми.

**Маддә 58. Үз вакытында пенсионер тарафыннан алынмаган пенсияне түләү**

Әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән затлар арасыннан пенсионерларга һәм аларның гаилә әгъзаларына исәпләнгән, тик аларга үз вакытында кирәкмәгән пенсия суммасы үткән вакыт өчен түләнелә, әмма мөрәҗәгать итү алыннан өч елдан да күбрәк вакыт өчен түләнми.

Әгәр пенсионер үз вакытында пенсия суммаларын пенсия билгели һәм түли торган орган гаебе аркасында алмаган булса, алар үткән вакыт өчен бернинди срок белән чикләнмичә түләнә.

**Маддәләр 59-60. Төшереп калдырылган. - 10.01.2003 нан 2-ФЗ номерлы Федераль канун.**

**Маддә 61. Үз көчен югалткан. - 03.12.2007 нән 319-ФЗ номерлы Федераль канун.**

**Маддә 62. Хаталарны ачыклаган очракта пенсиядән тотып калу һәм тиешле еллар эшләгән өчен пенсияне түләү тәртибе**

(03.04.2017 нән 63-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

Әлеге Канун нигезендә түләнә торган пенсиядән тотып калу (милек түләтү өлешендә) суд карарлары, нотариаль контораларның башкарма язулары һәм башка карарлар нигезендә башкарыла, аларны башкару канунчылык нигезендә суд карарларын үтәү өчен билгеләнгән тәртиптә башкарыла. Пенсионерның гаеп эшләре нәтиҗәсендә аңа артык түләнгән пенсия яки пособиенең суммасы тиешле пенсия органы карары нигезендә ай саен түләнергә тиешле пенсиянең 20 процентыннан артмаган күләмдә башка нигезләр буенча  тотып калулардан тыш. Барлык пенсия өчен түләтү очракларында да пенсионерга тиешле пенсиянең 50 процентыннан да ким түгел суммасы саклана.

Пенсияләрнең һәм пособиеләрнең артык түләнгән суммалары буенча бурычларны тулысынча каплауга кадәр пенсияне түләү туктатылса, калган артык түләнгән сумма суд тәртибендә түләтелә.

Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләгәндә җибәрелгән хаталар ачыкланган очракта бу хатаны Рәсәй Федерациясе канунчылыгы нигезендә бетерү башкарыла.

(Өченче өлеш 03.04.2017 нән 63-ФЗ номерлы Федераль канун тарафыннан кертелгән)

Бердәнбер керем чыганагы булып торган пенсия билгеләнгәннән көннән соң өч ел узгач табып алынган хатаны бетерү сәбәпле пенсионер тиешле елларны эшләгән өчен пенсиягә хокукын югалтса,  пенсионерның пенсияне хокуксыз билгеләүгә китергән гаепле гамәлләре булмаса, пенсия органы хата ачыкланган көнгә түләнә торган пенсиянең шундый ук күләмен түләү турында карар кабул итә.

(дүртенче өлеш 03.04.2017 нән 63-ФЗ номерлы Федераль канун тарафыннан кертелгән)

Әлеге матдәнең дүртенче өлешендә күрсәтелгән сумма пенсионер әлеге канун нигезендә пенсияне алу хокукына ия булганчы яки Рәсәй Федерациясе канунчылыгы нигезендә билгеләнгән теләсә кайсы башка пенсияне (тупланма пенсия һәм социаль пенсиядән тыш) билгеләү хокукына ия булганчы ай саен түләнә һәм Рәсәй

Федерациясе канунчылыгы нигезендә ел саен арттырылырга (индексацияләнергә) тиеш.

(бишенче өлеш 03.04.2017 нән 63-ФЗ номерлы Федераль канун тарафыннан кертелгән)

Аңа хокук булмау яки пенсиянең башка төренә хокук алу сәбәпле тиешле елларны эшләгән өчен пенсия түләүен туктату күрсәтелгән шартлар барлыкка килгән айдан соң килүче айның 1 нче числосыннан башкарыла.

(алтынчы өлеш 03.04.2017 нән 63-ФЗ номерлы Федераль канун тарафыннан кертелгән)

**Маддә 63. Пенсионер үлгән очракта пенсияне түләү**

Пенсионерга әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән затлар һәм аларның гаилә әгъзалары арасыннан исәпләнгән һәм аның үлеме сәбәпле алынмаган пенсия суммасы үлгән пенсионерның гаилә әгъзаларына түләнә, әгәр алар аны җирләгәндә әлеге суммаларны мирас составына кертмәгән булсалар. Башка очракларда пенсионерның үлеме сәбәпле алынмаган пенсия күләме аның варисларына Рәсәй Федерациясе граждан канунчылыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми нигезләрдә түләнә.

**Маддә 64. Рәсәй Федерациясе территориясеннән читтә даими яшәүгә чыкканда пенсияләрне түләү**

(22.02.2017 нән 20-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

Әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән Рәсәй Федерациясе территориясеннән читкә даими яшәүгә чыгучы (чыгып киткән) затларга һәм аларның гаилә әгъзаларына әлеге Канунда каралган пенсияләр Рәсәй Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләгән тәртиптә түләнә, әгәр Рәсәй Федерациясенең халыкара килешүләре тарафыннан башкасы билгеләнмәгән булса.

**Маддә 65. Пенсия мәсьәләләре буенча бәхәсләр**

Әлеге Канунның 1 маддәсендә күрсәтелгән затларга һәм аларның гаиләләренә пенсияне билгеләү һәм түләү, артык түләнгән пенсия һәм пособиеләрне түләттерү мәсьәләләре буенча бәхәсләр югары дәрәҗәдә булган органнар тарафыннан пенсия органнарының буйсыну тәртибендә Рәсәй Федерациясе Оборона министрлыгы, Рәсәй Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы, Җәзаларны үтәтү федераль хезмәте, Рәсәй Федерациясе федераль иминлек хезмәте, Рәсәй Федерациясе Генераль прокуратурасы, Рәсәй Федерациясе Тикшерү комитеты тарафыннан яисә Рәсәй Федерациясе канунчылыгы нигезендә суд тәртибендә хәл ителә.

(28.11.1995 нән 186-ФЗ номерлы, 21.07.1998 нән 117-ФЗ номерлы, 29.06.2004 нән 58-ФЗ номерлы, 04.06.2014 нән 145-ФЗ номерлы, 03.07.2016 нән 305-ФЗ номерлы федераль кануннар редакциясендә)

Рәсәй Федерациясе

Президенты

Б. ЕЛЬЦИН

Мәскәү, Рәсәй Советлар Йорты

1993 елның 12 феврале

N 4468-1